Петр Алексеевич Днепровның тууына 100 ел (16.01.1919–1974)

– 100 лет со дня рождения Петра Алексеевича Днепрова (16.01.1919–1974)

Михаил Ефимович Дряничкинның тууына 110 ел (04.12.1909–1945)
– 110 лет со дня рождения Михаила Ефимовича Дряничкина (04.12.1909–1945)

Михаил Григорьевич Елисеевның тууына 120 ел (07.11.1899–1943)
– 120 лет со дня рождения Михаила Григорьевича Елисеева (07.11.1899–1943)

Петр Артемьевич Ивановның тууына 110 ел (1909–1944)
– 110 лет со дня рождения Петра Артемьевича Иванова (1909–1944)

Тамерлан Кәрим улы Ишмөхәммәтовның тууына 100 ел (08.08.1919–1995)
– 100 лет со дня рождения Тамерлана Каримовича Ишмухамедова (08.08.1919–1995)

Әхмәдулла Хаҗи улы Ишмөхәммәтовның тууына 100 ел (07.11.1919–1952)
– 100 лет со дня рождения Ахмадуллы Хозеича (Хазиевича) Ишмухаметова (07.11.1919–1952)

Галимҗан Камали улы Камалиевның тууына 100 ел (15.07.1919–1993)
– 100 лет со дня рождения Галимзяна Камалеевича Камалеева (15.07.1919–1993)

Эдуард Павлович Княгиничевның тууына 90 ел (29.11.1929–2000)
– 90 лет со дня рождения Эдуарда Павловича Княгиничева (29.11.1929–2000)

Степан Петрович Комлевның тууына 100 ел (08.04.1919–1944)
– 100 лет со дня рождения Степана Петровича Комлева (08.04.1919–1944)

Анатолий Михайлович  Коняевның тууына 110 ел (30.03.1919–1992)
– 100 лет со дня рождения Анатолия Михайловича Коняева (30.03.1919–1992)

Павел Степанович Коростелевның тууына 100 ел (24.04.1919–1995)
– 100 лет со дня рождения Павла Степановича Коростелева (24.04.1919–1995)

Михаил Васильевич Красавинның тууына 100 ел (22.10.1919–1992)

– 100 лет со дня рождения Михаила Васильевича Красавина (22.10.1919–1992)

Тимерәй Кубакай улы Кубакаевның тууына 100 ел (01.07.1919–1943)

– 100 лет со дня рождения Тимирая Кубакаевича Кубакаева (01.07.1919–1943)

Николай Евгеньевич Кульчицкийның тууына 90 ел (27.07.1929–1982)

– 90 лет со дня рождения Николая Евгеньевича Кульчицкого (27.07.1929–1982)

Александр Петрович Кулясовның тууына 100 ел (10.03.1919–1945)

– 100 лет со дня рождения Александра Петровича Кулясова (10.03.1919–1945)

Григорий Михайлович Машанинның тууына 100 ел (13.02.1919–1988)

– 100 лет со дня рождения Григория Михайловича Машанина (13.02.1919–1988)

Гатаулла Мирзаһит улы Минаев (Николай Сергеевич Орлов)ның тууына 100 ел (29.12.1919–1982)

–100 лет со дня рождения Гатауллы Мирзахитовича Минаева (Николая Сергеевича Орлова) (29.12.1919–1982)

Павел Андреевич Мироновның тууына 100 ел (12.12.1919–1945)

– 100 лет со дня рождения Павла Андреевича Миронова (12.12.1919–1945)

Кузьма Васильевич Новоселовның тууына 100 ел (08.02.1919–1985)

– 100 лет со дня рождения Кузьмы Васильевича Новоселова (08.02.1919–1985)

Иван Андреевич Норкинның тууына 100 ел (24.09.1919–2002)

– 100 лет со дня рождения Ивана Андреевича Норкина (24.09.1919–2002)

Наум Григорьевич Пейсаховскийның тууына 110 ел (10.04.1909–1999)

– 110 лет со дня рождения Наума Григорьевича Пейсаховского (10.04.1909–1999)

Василий Григорьевич Пискуновның тууына 100 ел (28.02.1919–1994)

– 100 лет со дня рождения Василия Григорьевича Пискунова (28.02.1919–1994)

Фәйзерахман Әхмәтҗан улы Сабировның тууына 100 ел (05.09.1919–1990)

– 100 лет со дня рождения Файзрахмана Ахмедзяновича Сабирова (05.09.1919–1990)

Сәйтнәфи Сәидвәлиевнең тууына 100 ел (29.05.1919–1983)
– 100 лет со дня рождения Сейтнафе Сейтвелиева (29.05.1919–1983)

Василий Иванович Сиговның тууына 100 ел (22.06.1919–1987)
– 100 лет со дня рождения Василия Ивановича Сигова (22.06.1919–1987)

Михаил Владимирович Суднишниковның тууына 100 ел (21.11.1919–1985)
– 100 лет со дня рождения Михаила Владимировича Суднишникова (21.11.1919– 1985)

Сергей Михайлович Фадеевның тууына 100 ел (08.04.1919–1952)
– 100 лет со дня рождения Сергея Михайловича Фадеева (08.04.1919–1952)

Нурулла Гарифулла улы Фазлаевның тууына 110 ел (06.03.1909–1997)
– 100 лет со дня рождения Нуруллы Гарифулловича Фазлаева (06.03.1909–1997)

Павел Григорьевич Фроловның тууына 110 ел (17.07.1909–1991)
– 110 лет со дня рождения Павла Григорьевича Фролова (17.07.1909–1991)

Филипп Михайлович Черокмановның тууына 120 ел (16.11.1899–1978)
– 120 лет со дня рождения Филиппа Михайловича Черокманова (16.11.1899–1978)

Галимҗан Нургаяз улы Шаһвәлиевнең тууына 100 ел (23.12.1919–1982)
– 100 лет со дня рождения Галимзяна Нургаязовича Шагвалеева (23.12.1919–1982)

Россия Федерациясе Герое Виктор Федорович Еринның тууына 75 ел (17.01.1944–2018)
– 75 лет со дня рождения Героя Российской Федерации Виктора Федоровича Ерина (17.01.1944–2018)

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**

Ханин Л. Советлар Союзы Геройлары – Татарстан уллары. – Казан: Татар. китап нәшр., 1966. – 640 б.

Советлар Союзы геройлары – якташларыбыз: әдәби докум. очерклар һәм язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 680 б.

**** Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Герои Советского Союза – наши земляки: сб. докум. очерков и зарисовок: в 3-х кн. /сост. З.И.Гильманов, А.К.Айнутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982–1985.

Батырлар китабы = Книга Героев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 395 б. – На татар. и рус. яз.

Ханин Л. Герои Советского Союза – сыны Татарии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1963. – 680 с.

Герои Казани = Казан Каһарманнары /авт.-сост.: М.В.Черепанов, Е.В.Панов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – 335 с., с ил.

**Түбәндә исемнәре күрсәтелгән якташларыбыз – Дан ордены тулы кавалерларының 2019 елда юбилейлары була:***

**В 2019 году исполняется кавалерам ордена Славы трех степеней – нашим землякам:***

Николай Федорович Пестоновның тууына 120 ел (19.05.1899–1974)
– 120 лет со дня рождения Николая Федоровича Пестонова (19.05.1899–1974)

---

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**
*** Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Кавалеры ордена Славы трех степеней = Дан орденының тулы кавалерлары. – Казань: Книга Памяти, 2005. – 247 с. – На рус. и татар. яз.

**Түбәндә исемнәре күрсәтелгән якташларыбыз – Социалистик Хезмәт Геройларының 2019 елда юбилейлары була:***

**В 2019 году исполняется Героям Социалистического труда – нашим землякам:***

Нургали Барый улы Бариевның тууына 100 ел (01.01.1919–1998)
– 100 лет со дня рождения Нургали Бариевича Бариева (01.01.1919–1998)

Геннадий Сергеевич Баштанюкка 70 яшь (22.10.1949)
– 70 лет Геннадию Сергеевичу Баштанюку (22.10.1949)

Александр Иванович Бирюлинның тууына 90 ел (08.12.1929–1992)
– 90 лет со дня рождения Александра Ивановича Бирюлина (08.12.1929–1992)

Шакир Гали улы Галиевнең тууына 100 ел (02.06.1919–1988)
– 100 лет со дня рождения Шакира Галеевича Галеева (02.06.1919–1988)

Самат Сәмигулла улы Гатауллинга 90 яшь (10.07.1929)
– 90 лет Самату Самигулловичу Гатауллину (10.07.1929)

Мөгаллим Минһаҗ улы Гыймазовның тууына 100 ел (03.01.1919–1982)
– 100 лет со дня рождения Мугаллима Мингазовича Гимазова (03.01.1919–1982)

Әхәт Шәрифулла улы Гобәйдуллинның тууына 100 ел (02.11.1919–1983)
– 100 лет со лня рождения Ахата Шарифулловича Губайдуллина (02.11.1919–1983)

Сафиулла Сәлимулла улы Гобәйдуллинның тууына 90 ел (15.08.1929–2010)
– 90 лет со дня рождения Сафиуллы Салимулловича Губайдуллина (15.08.1929–2010)

Николай Иванович Захаровның тууына 90 ел (20.09.1929–2002)
– 90 лет со дня рождения Николая Ивановича Захарова (20.09.1929–2002)

Елизавета Гурьевна Ласточкинаның тууына 150 ел (05.06.1869–1967)
– 150 лет со дня рождения Елизаветы Гурьевны Ласточкиной (05.06.1869–1967)

Николай Васильевич Лемаевның тууына 90 ел (01.11.1929–2000)

– 90 лет со дня рождения Николая Васильевича Лемаева (01.11.1929–2000)

Мисбах Мәүли улы Мәүлиевнең тууына 90 ел (10.02.1929–2011)
– 90 лет со дня рождения Мисбаха Мавлеевича Мавлеева ( 10.02.1929–2011)

Аркадий Васильевич Мариничның тууына 110 ел (18.12.1909–1989)
– 110 лет со дня рождения Аркадия Васильевича Маринича (18.12.1909–1989)

Равил Мифтах улы Низаметдиновның тууына 90 ел (10.03.1929–1993)
– 90 лет со дня рождения Равиля Мифтаховича Низаметдинова (10.03.1929–1993)

Леонтий Степанович Петровның тууына 110 ел (1909–1986)
– 110 лет со дня рождения Леонтия Степановича Петрова (1909–1986)

Вафа Сафа улы Сафинның тууына 100 ел (23.10.1919–2003)
– 100 лет со дня рождения Вафы Сафиновича Сафина (23.10.1919–2003)

Любовь Евгеньевна Смирновага 75 яшь (16.07.1944)
– 75 лет Любовь Евгеньевне Смирновой (16.07.1944)

Николай Алексеевич Соболевның тууына 100 ел (05.05.1919–2007)
– 100 лет со дня рождения Николая Алексеевича Соболева (05.05.1919–2007)

Андрей Александрович Хабаровның тууына 100 ел (15.05.1919–1998)
– 100 лет со дня рождения Андрея Александровича Хабарова (15.05.1919–1998)

Гыйльми Шакир улы Шакировның тууына 90 ел (1929–1991)
– 90 лет со дня рождения Гильми Шакировича Шакирова (1929–1991)

Владимир Александрович Энгельгардның тууына 125 ел (03.12.1894–1984)
– 125 лет со дня рождения Владимира Александровича Энгельгарда (03.12.1894–1984)

**Түбәндә исемнәре күрсәтелгән**
**якташларыбыз – Хезмәт Даны ордены тулы кавалерларының 2019 елда юбилейлары була:***
**В 2019 году исполняется**
**полным кавалерам ордена Трудовой Славы – нашим землякам:***

Виктор Кузьмич Проценконың тууына 80 ел (16.06.1939–2007)
– 80 лет со дня рождения Виктора Кузьмича Проценко (16.06.1939–2007)

Данил Зияф улы Фәтхуллинга 70 яшь (02.01.1949)
– 70 лет Данилу Зияфовичу Фатхуллину (02.01.1949)

---

*** Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**
*** Очерки о жизненном пути Героев см.:**

Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы – наши земляки = Социалистик Хезмәт геройлары һәм Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – безнең якташларыбыз. – Казань, 2003. – 232 с. – На рус. и татар. яз.

Герои Труда Татарии 1920–1938 гг.: док. очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 304 с.

Герои Социалистического Труда (1938–1978 гг.): (док. очерки). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 383 с.

Герои Социалистического Труда Татарии: док. очерки. Кн.2. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 352 с.

**19 гыйнвар** | **Хөсәен Уразиков**
**19 января** | **Хусаин Уразиков**
**1894–1977**
**туuына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Татар театры тарихында бай иҗат мирасы калдырган олы шәхесләребезнең берсе Хөсәен Ибраһим улы Уразиков 1894 елның 7 (19) гыйнварында Саратов губернасының Дергачев өязе Сәфәр авылында туа. 1908 елда Җаек (Уральск) шәһәренә күчеп китә; биредә мәдрәсәдә укый, бер үк вакытта рус мәктәбендә дә дәресләр ала.

Х.Уразиков Самара театр студиясендә укуын К.Тинчурин һәм З.Солтанов җитәкчелегендә башлап җибәрә һәм аны 1920 елда тәмамлый. Аннары төрле шәһәрләрдә – Хива, Бохара, Ташкент, Алма-Ата, Бишкәк, Оренбург, Мәскәү, Әстерхан татар театрларында эшли. 1930 елдан – Казанда, Татар академия театрында. 1944–1948 елларда театрның сәнгать җиткчесе була.

Х.Уразиков – күренекле, мәшһүр артист. Илле еллык сәхнә эшчәнлеге дәверендә аның тарафыннан барлыгы 160 ка якын роль уйналган. Артистның осталык диапазоны гаҗәеп киң, төрле характердагы образлар аша күпкырлы таланты ачыла. Шуларның Ишан, Мисбах хаҗи (К.Тинчурин, «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр»), Колый Тархан, Бикәмәт (Н.Исәнбәт, «Хуҗа Насретдин», «Зифа»), Имәнкол, Биктимер (Т.Гыйззәт, «Наемщик», «Ташкыннар») кебекләре – татар артисты тудырган иң гүзәл образлар.

Шул ук вакытта Х.Уразиков рус һәм чит ил классиклары әсәрләрендә дә зур һәм җаваплы рольләр башкара. Алар арасында – Вурм (Ф.Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Глостер (У.Шекспир, «Король Лир»), Левшин, Иван Коломийцев (М.Горький, «Дошманнар», «Соңгылар») һ.б.

Режиссер буларак Х.Уразиковның беренче тәҗрибәсе 1922 елда башлана. Ул Алма-Атада К.Тинчуринның «Сакла, шартламасын» комедиясен сәхнәләштерә. Ә профессиональ режиссура белән 1935 елдан шөгыльләнә – Татар академия театрында К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасын куя, Т.Гыйззәтнең «Данлы көннәр» (1936), Е.Амантов һәм К.Тумашева белән берлектә Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» (1940), К.Симоновның «Безнең шәһәрнең егете», Н.Исәнбәтнең «Идегәй» (1941) трагедиясен, М.Гали белән берлектә «Каюм Насыри» һ.б. спектакльләрне сәхнәләштерә.

Х.Уразиков тарафыннан куелган спектакльләрнең күбесе заман темасына багышланган. Ул сәхнәләштергән М.Әмирнең «Миңлекамал»,

Б.Лавреневның «Диңгездәгеләр өчен», М.Кәримнең «Ялгыз каен», Н.Исәнбәтнең «Зифа», Ш.Шаһгалинең «Таң атканда», Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» кебек әсәрләр заман проблемалары белән бәйләнгән. Кайбер спектакльләрне ул берничә тапкыр кабатлап та куя.

Х.Уразиков 1933–1965 елларда Казан театр училищесында укыта.

Х. Уразиковның киң һәм күпкырлы иҗаты югары бәяләнә: 1945 елда аңа ТАССРның халык артисты, 1950 елда РСФСРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр, 1957 елда Ленин ордены бирелә.

Х. И.Уразиков 1977 елның 24 августында вафат була.

В ряду выдающихся деятелей татарской театральной культуры имя Хусаина Уразикова занимает особое место. Он родился 7 (19) января 1894 года в деревне Сафаровка Дергачевского уезда Саратовской губернии (ныне Саратовская область). В 1908 году переезжает в город Уральск, где учебу в медресе совмещает с занятиями в русской школе.

В 1920 году Х.Уразиков окончил Самарскую театральную студию, учился у К.Тинчурина и З.Султанова. Затем работал в татарских театрах Хивы, Бухары, Ташкента, Оренбурга, Алма-Аты, Бишкека, Астрахани, Москвы. С 1930 года – актер и режиссер Татарского академического театра. В 1944–1948 годах – его художественный руководитель.

Х.Уразиков – признанный мастер татарской сцены. За пятьдесят лет сценической деятельности им было сыграно около 160 ролей. В разнообразных по масштабам и характеру ролям раскрывается разносторонний талант актера. Созданные Х.Уразиковым образы – Ишан, Мисбах хаджи («Голубая шаль», «Без ветрил» К.Тинчурина), Колый Тархан и Бикамет («Ходжа Насретдин» и «Зифа» Н.Исанбета), Иманкул, Биктимер («Наемщик», «Потоки» Т.Гиззата) и многие другие – вошли в золотой фонд лучших актерских работ татарского театра.

Х.Уразиков исполняет также большие роли в спектаклях русских и зарубежных авторов, среди которых – Вурм (Ф.Шиллер «Коварство и любовь»), Глостер (У.Шекспир «Король Лир»), Левшин, Иван Коломийцев (М.Горький «Враги», «Последние») и др.

Первые режиссерские опыты Х.Уразикова относятся к 1922 году. Он ставит комедию «Берегись, взорвется» К.Тинчурина в Алма-Ате. А профессионально заниматься режиссурой начал в 1935 году, когда на сцене Татарского академического театра поставил драму «Первые цветы» К.Тинчурина. Х. Уразиков осуществил постановки пьес: «Данлы көннәр» («Славная эпоха») Т.Гиззата (1936), совместно с Е.Амантовым и К.Тумашевой – комедии «Ходжа Насретдин» Н.Исанбета (1940), «Безнең

шәһәрнең егете» («Парень из нашего города») К.Симонова, трагедии «Идегей» Н.Исанбета (1941), «Каюм Насыри» совместно с М.Гали и др.

Режиссерская деятельность Х.Уразикова пронизана духом современности. Режиссер подмечает и понимает все изменения, происходящие вокруг, подвергает глубокому анализу все новое в окружающем его мире. Такие спектакли Х.Уразикова, как «Минникамал» М.Амира, «Диңгездәгеләр өчен» («За тех, кто в море») Б.Лавренева, «Ялгыз каен» («Одинокая береза») М.Карима, «Зифа» Н.Исанбета, «Таң атканда» («На заре») Ш.Шахгали, «Зөбәйдә – адәм баласы» («Зубайда – дитя человеческое») Ш.Хусаинова и другие, являются отражением его знания и понимания современности. Некоторые постановки возобновлялись им же по несколько раз.

В 1933–1965 годах Х.Уразиков преподает в Казанском театральном училище.

Широкая и многогранная деятельность Х.И.Уразикова была высоко оценена: в 1945 году ему было присвоено почетное звание народного артиста ТАССР, в 1950 году – заслуженного артиста РСФСР; в 1957 году он удостоен Ордена Ленина.

Х.И.Уразиков умер 24 августа 1977 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан, 2014. – 584 б. – Уразиков Хөсәен Ибраһим улы. – Б. 495-511.

**Арсланов Г.** Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б. – Онытылмас спектакльләр. Хөсәен Уразиков. – Б. 141-165.

**Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 100 ел:** альбом: 2 томда. Т.2. – Казан: Заман; Татар. кит. нәшр., 2009. – 567 б.: фотолар б-н. – Уразиков Хөсәен Ибраһим улы. – Б. 133.

**Корбан Р.** Театр сәнгатенең көзгесе //Шәһри Казан. – 1994. – 1 февр.

**Галимҗанова Л.** Театр тарихында аның исеме мәңгелек //Шәһри Казан. – 2004. – 27 февр.

**Арсланов М.Г**. Актер. Режиссер. Драматург. Педагог: очерк жизни и творчества Хусаина Уразикова. – Казань, 2006. – 240 с.

**Арсланов М.Г.** Хусаин Уразиков: очерк жизни и творчества. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 168 с.

**Арсланов Г.** Хусаин Уразиков //Народные артисты. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – С. 328-331.

**Гимранова Д.** Феномен Уразикова //Известия Татарстана. – 1994. – 25 янв.

**12 март** **Кондрат Евдокимович Максимов**
**12 марта** **1894–1981**
**туына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Рәссам Кондрат Евдокимович Максимов 1894 елның 12 мартында Вятка губернасы Уржум өязе Шишкино авылында туа. 1914–1917 елларда (бүленеп) Казан сынлы сәнгать мәктәбендә укый. 1917–1927 елларда туган авылында сал агызучы булып эшли.

1927–1929 елларда Лениград рәссамы М.М.Гужавин җитәкчелегендә яңадан нәкышь белән шөгыльләнә.

1930–1935 елларда ул Казанда сал агызу тәҗрибә станциясендә хезмәт куя.

К.Максимов 1930 нчы еллар уртасыннан нәкышь сәнгате өлкәсендә актив эшли башлый, Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан районнарында йөри, миниатюр этюдлар циклын яза (100гә якын әсәр), шулар нигезендә тыл хезмәтчәннәренә багышланган «Салларда» (1943), «Урман кисүчеләрнең төн куну урыны», «Орлык фондына ашлык тапшыру» (икесе дә – 1944) исемле зур картиналар иҗат итә.

1940 нчы еллар уртасында рәссам соңрак үз иҗатында үзәк урынны алган пейзаж жанрына мөрәҗәгать итә. К.Максимовның зур мирасында Кавказ, Кырым, Украина, рус Төньягы пейзажлары да аз түгел, урта рус пейзажы аңа аеруча якын. Ул картиналарында Татарстанның Идел-Кама киңлекләрен, Вятка урманнарын тасвирлый. К.Максимов И.И.Шишкин нигез салган рус реалистик пейзажы традицияләрен дәвам итә, үстерә: «Кама» (1945), «Арыш» (1953), «Урманлы офыклар» (1953), «Вятка киңлекләре» (1969), «Чыршы урманында көн уртасы» һ.б. Иҗатының зур өлеше камера-лирик һәм экияти-романтик характерда: «Абага чәчәк аткан төн» (1946), «Аленушка» (1950), «Тыелган урман» (1959), «Алабуга. 1918 елда кызыл партизаннарны аткан урын» (1967) һ.б. пейзажларында тирән сагыш чагыла.

К.Максимов шулай ук табигатьне, күптөрле чәчәкләр һәм җиләк-җимешләр дөньясын тасвирлаучы натюрморт жанрында да уңышлы эшли.

К.Е.Максимов күпсанлы күргәзмәләрдә катнаша: 1928 һәм 1929 елларда Ленинградта, Мәскәүдә Бөтенроссия һәм РСФСРның автономияле 16 республикасы күргәзмәләре, Казандагы барлык республика күргәзмәләре. Берничә мәртәбә аның шәхси күргәзмәләре куела.

Әсәрләре Татарстан Республикасының Милли музеенда, Татарстанның Сынлы сәнгать музеенда, Яр Чаллы һәм Әлмәттә картиналар галереяларында саклана.

К.Е.Максимовка 1957 елда ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1960 елда ТАССРның халык рәссамы, 1974 елда РСФСРның атказанган рәссамы дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «За доблестный труд в Великой Отчественной войне 1941–1945 гг.» медале белән бүләкләнә.

К.Е.Максимов 1981 елның 1 октябрендә вафат була.

Живописец Кондрат Евдокимовч Максимов родился 12 марта 1894 года в деревне Шишкино Уржумского уезда Вятской губернии. В 1914–1917 годах (с перерывами) учится в Казанской художественной школе. В 1917–1927 годах работает на лесосплаве в родной деревне.

В 1927–1929 годах возобновляет занятия живописью под руководством ленинградского художника М.М.Гужавина.

В 1930–1935 годах работает в Казани на опытной станции лесосплава.

С середины 1930-х годов К.Максимов начинает активно заниматься живописью. В годы Великой Отечественной войны выезжает в районы Татарстана. Создает обширный цикл миниатюрных этюдов (около 100 произведений), на основе которых позднее были написаны его полотна «На плотах» (1943), «Ночлег лесорубов», «Сдача зерна в семенной фонд» (оба – 1944), посвященные труженикам тыла.

В середине 1940-х годов художник обращается к жанру пейзажа, который стал основным в его творчестве. В обширном наследии К.Максимова немало пейзажей Кавказа, Крыма, Украины, русского Севера, особенно близка мастеру тема среднерусской полосы. Художник запечатлел на своих полотнах берега и просторы Волги и Камы, вятские леса. К.Максимов последовательно развивает традиции русского реалистического пейзажа, основоположником которого является И.И.Шишкин: «Кама» (1945), «Рожь» (1953), «Лесные дали» (1953), «Вятские просторы» (1969), «Полдень в сосновом лесу» (1973) и др. В его творчестве немало произведений камерно-лирического и сказочно-романтического характера: «Ночь, когда цветет папортник» (1946), «Аленушка» (1950), «Заповедный лес» (1959), «Елабуга. Место расстрела красных партизан в 1918 году» (1967). К.Максимов плодотворно работает также в жанре натюрморта, отображающего многообразный мир цветов и плодов.

К.Максимов – участник многих выставок: в 1928 и 1929 годах в Ленинграде, всероссийских выставках, выставках шестнадцати автономных республик РСФСР в Москве, республиканских выставок в Казани и др. Произведения художника хранятся в Национальном музее РТ, Государственном музее изобразительных искусств РТ, картинных галереях городов Набережные Челны и Альметьевск.

К.Е.Максимов удостоен почетных званий: заслуженный деятель искусств ТАССР (1957), народный художник РСФСР (1960). Награжден Орденом Трудового Красного Знамени, медалью «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.».

К.Е.Максимов умер 1 октября 1981 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Хәеров Г.** Кондрат Максимовның кышкы ызбасы //Татарстан. – 2016. – № 2. – Б. 68-71.

**Галиуллина М.** Йөрәгендә шаулый кара урман //Мәдәни җомга. – 2014. – 20 июнь (№ 24). – Б. 12.

**Кара урман шавыннан иркәләнде күңеле**: [Сынлы сәнгать музеенда К.Максимовның 110 еллгына багышланган күргәзмә тур.] //Мәдәни җомга. – 2004. – 9 апр. (№ 14). – Б. 12.

**Братышева В.** Матурлык җырчысы: Татарстанның халык рәссамы К.Максимовның тууына – 100 ел //Шәһри Казан. – 1994. – 15 март.

**Червонная С.М.** Художники Советской Татарии: (мастера изобразительного искусства Союза художников ТАССР). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 464 с. – Максимов Кондрат Евдокимович. – С. 205-208.

**Народный художник ТАССР Кондрат Евдокимович Максимов:** 75 лет со дня рождения. 40 лет творческой деятельности: каталог выставки /авт. вступ. ст. и сост. А.Б.Файнберг. – Казань, 1970.

**Хаиров А.** Зимняя избушка Кондрата Максимова //Татарстан. – 2016. – № 2. – С.74-77.

**Черняева Е.** Счастье в каждом в змахе кисти: [в Музее изобразительных искусств открылась выставка, посвященная 110-й годовщине со дня рождения художника] //Звезда Поволжья. – 2004. – 16-22 сент. – С. 4.

**Христофоров И.** Казань должна гордиться своими художниками: [о творчестве художника К.Максимова и проблеме сохранения его произведений] //Конец недели. – 2000. – 11 нояб.

**Казаков В.** Немного солнца от «уходящей натуры» //Респ. Татарстан. – 1994. – 12 марта.

**Сафин М.** И кистью, и душой //Сов. Культура. – 1981. – 18 авг. – С.4.

**март** **Мәхбүбҗамал Акчурина**
**Махбубджамал Акчурина**
**1869–1948**
**туууына 150 ел**
**150 лет со дня рождения**

Беренче рус революциясе елларында матбугатка килгән хатын-кызлар арасында Мәхбүбҗәмал Акчурина үзенчәлекле урын биләп тора. Ул бик күп тармаклы атаклы Акчуриннар нәселеннән; 1869 елның март аенда Саратов губернасы Кузнецк өязе Димау авылы имамы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне атасыннан ала, соңрак үзлегеннән укып, туган авылында мөгаллимә була.

1892 елда аны Самара губернасындагы Савинка авылына кияүгә биргәннәр. Монда да ул укытучылык эшен дәвам итә; гомерен кызлар укытуга багышлый, хатын-кызларны агарту-тәрбияләү эшенә актив керешә, үзенең әсәрләре белән матбугатта да күренә башлый.

М.Акчуринаның әдәби эшчәнлеге берничә юнәлештә бара. 1908 елдан башлап ул Оренбургта чыга торган «Шура», соңга таба Казандагы «Сөембикә» журналларында бала тәрбиясе, гаилә-көнкүреш гигиенасы мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрен бастыра.

Шулай ук 1908–1915 еллар арасында көндәлек матбугат битләрендә, аерым басмалар булып әдибәнең реаль тормыш вакыйгаларына нигезләп язылган хикәя һәм очерклары дөнья күрә. Язучының проза әсәрләре арасында «Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә (күренеш)» һәм «Шәфкатьсез ата, яки мишәрләр тормышы» хикәяләре игътибарга лаек. 1914 елда басылып чыккан (беренчесе – «Шура» журналында, икенчесе – аерым басма булып Оренбургта) бу әсәрләрдә мишәр авылы тормышында булган вакыйгалар сурәтләнә, татар хатын-кызларының аяныч тормышы күрсәтелә.

М. Акчуринаның 1911 елда «Шура» журналында басылган «Иске әдәбиятымыз» исемле очеркы игътибарга лаек. Ул, матбугатта беренчеләрдән булып, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, язма мирасыбызны барлау һәм өйрәнү кирәклеге турында яза. «Сәйфелмөлек», «Таһир илә Зөһрә» поэмаларына тулы анализ ясый. Язучы мондый әсәрләрнең әхлакый кыйммәтен күрсәтә, аларның бөтен халыкка, бигрәк тә яшь буыннарга әхлакый-эстетик тәрбия чыганагы булуына аеруча игътибар итә.

Октябрьдән соң М.Акчурина әдәби-публицистик иҗат эшеннән ераклаша. 1929 елда ул Баку шәһәренә күчеп китә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши.

М.Акчурина 1948 елда вафат була.

Среди писательниц, пришедших в литературу в годы первой русской революции, Махбубджамал Акчурина занимает особое место. Представительница знаменитого рода симбирских купцов Акчуриных, она родилась в марте 1869 года в деревне Дема Кузнецкого уезда Саратовской

губернии в семье муллы. Первоначальное образование получает от отца, занимается самообразованием, сама обучает девочек в родной деревне.

В 1892 году ее выдают замуж в деревню Савинка Самарской губернии, где она продолжает учительствовать.

Литературная деятельность М.Акчуриной охватывает разные аспекты. С 1908 года она публикует свои статьи, посвященные проблемам воспитания детей, гигиены семьи, жилища, в журналах «Шура» (Оренбург) и «Сююмбика» (Казань).

В 1908–1915 годах на страницах периодической печати и отдельными изданиями публикуются рассказы и очерки, созданные на основе реальных событий. Среди художественных произведений М.Акчуриной особое место занимают рассказы «Сцена из жизни мишарей» и «Жестокий отец, или Жизнь мишарей», опубликованные в 1914 году (первый – в журнале «Шура», второй – отдельным изданием в Оренбурге). В них отображены реальные картины жизни татарской (мишарской) деревни, описана нелегкая судьба татарской женщины.

Интересен очерк М.Акчуриной «Наша древняя литература», опубликованный в журнале «Шура» в 1911 году. В нем М.Акчурина одна из первых на страницах печати ставит вопрос о необходимости поиска, сбора и изучения произведений устного народного творчества и рукописного наследия. Писательница обращается к таким памятники древней литературы, как «Сайфульмулюк» и «Тагир Зухра», раскрывает значение произведений татарского народного творчества для нравственного и эстетического воспитания подрастающего поколения.

После октябрьских событий 1917 года М.Акчурина постепенно отходит от литературной деятельности. В 1929 году она переехала в Баку, где и прожила остаток своей жизни до 1948 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Акчурина М.** Хаммал Ягъкуб; Кыз егълату (XVIII гасырның ахырында булган вакыйга); Таш кием; Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә; Шәфкатьсез ата, яки мишәрләр тормышы; Көчсезләр, мәэюс вә пессимистларга гыйбрәт: [хикәяләр]; Иске әдәбиятымыз: [тәнкыйть мәкаләсе] //Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б.70-131. – Биогр. белешмә. – Б.70-71.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.1 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Мәхбүбҗәмал Акчурина. – Б. 23.

**Гайнуллин М.** Татар әдипләре: (иҗат портретлары). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 280 б. – Мәхбүпҗамал Акчурина. – Б. 211-216.

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: (элекке татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 399 б. – Акчурина Мәхбүбҗәмал. – Б. 13-14.

**Махмутова А.Х.** Женщины рода Акчуриных //Юсуф Акчура и симбирские купцы Акчурины.– Казань, 2017. – С. 141-149. – Махбубджамал Акчурина. – С. 144-147.

**март** **Әлмәт татар дәүләт драма театры Альметьевский татарский государственный драматический театр**

**1944**

**оештырылуына 75 ел**

**75 лет со дня основания**

Әлмәт шәһәренең киләчәктә кара алтын үзәге булачагы күздә тотылып, Әлмәт районы Башкарма комитеты 1944 елның 3 февралендә анда театр булдыру турында карар чыгара. ТАССР Министрлар Советы шул елның 20 мартында ул карарны раслый. Ул колхоз-совхоз театры буларак ачыла. 1951 елдан драма театры, 1985 елга кадәр күчмә театр була. Башта Мәдәният йортында урнаша, 1973 елда театрга яңа спектакльләр әзерләү өчен аерым эш бинасы бирелә. 1985 елда мәдәният йорты бинасы театр өчен үзгәртеп җиһазландырыла.

Труппа Казан театр училищесын тәмамлаучылардан һәм үзешчән сәнгатьтә катнашучылардан оеша. 1944 елның май ахырында Мәдәният йортында беренче спектакль – Р.Ишморатның «Кайту», 1945 елда М.Әмирнең «Миңлекамал» драмалары режиссер Ә.Галиев тарафыннан куелып, яңа коллективның иҗат мөмкинлекләрен күрсәтә.

1946–1950 елларда баш режиссер К.Халәпов Н.Гайсинның «Давыллар эчендә», «Таһир Биккинин», Э.Шамилнең «Егет сүзе», А.Әхмәтнең «Серләр» һ.б. пьесаларны сәхнәләштерә.

1950–1954 елларда театр репертуары А.Афиногеновның «Машенька», Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» (режиссеры Т.Кичубаев), А.Арбузовның «Яшьлек белән очрашу» (режиссеры С.Булатов), И.Франконың «Урланган бәхет» (режиссеры Г.Йосыпов) һ.б. белән баетыла.

1954–1958 елларда театрның баш режиссеры булып Сәет Булатов эшли. Аның тарафыннан Ш.Камалның «Томан арты», С.Кальметовның «Соңгы очрашу», М.Хәсәновның «Нурихан», «Рамай», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» пьесалары буенча куелган спектакльләр актерлар өчен җитди иҗат мәктәбенә әверелә.

Театрны 1963–1966 елларда җитәкләгән Г.Йосыпов коллективны профессиональ кадрлар белән тәэмин итүгә, актерлык осталыгын үстерүгә зур өлеш кертә. Театр репертуарында ул вакытта яшь драматурглар Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин, Ш.Хөсәенов пьесалары куела башлый.

1969–1972, 1975–1983 елларда театрны Г.Хөсәенов җитәкли. Аның тарафыннан Г.Мөсреповның «Козы-көрпеш һәм Баян-сылу» трагедиясе, Ч.Айтматовның «Анам кыры», Ш.Бикчуринның «Тальян моңы», К.Гольдониның «Тылсымлы кыз», А.Гыйләҗевның «Кар астында салкын чишмә», Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» (драматург, режиссеры Г.Хөсәенов, төп рольне башкаручы Д.Кузаева Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булалар), Ж.Ануйның «Антигона» әсәрләре буенча куелган спектакльләр театрны яңа биеклеккә күтәрә, коллективның җитлеккәнлеген күрсәтә.

1983–1988 елларда баш режиссер булып Рөстәм Абдуллаев эшли. Аның тарафыннан куелган К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр», Б.Васильевның «Ә таңнар гүзәл тынлыкта иде», Н.Фәттахның «Сармат кызы Сәринә» пьесалары җәмәгатьчелектә киң яңгыраш таба.

1964–1976 елларда 21 спектакль сәхнәләштергән Зәкия Туишева 1991 елда чираттагы режиссер булып театрга кайта һәм киң пландагы үзенчәлекле сәхнә полотноларын тудыруга ирешә. 1992 елда Казанда К.Тинчурин исемендәге республика театрлары фестивалендә З.Туишева тарафыннан куелган Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр» спектакле уңыш казана.

Соңгы елларда баш режиссер булып К.Вәлиев, Г.Каюмов эшли.

Әлмәт – театры халыкара, бөтенроссия театр фестивальләрендә катнашып, лауреат дипломнары ала.

Әлмәт театры – Татарстанның танылган коллективларының берсе. Бүген ул театр сәнгатенең иң катлаулы жанрлары, формалары һәм стильләренә көче җитәрлек профессиональ труппасы булган тотрыклы, заманча театр. Шәһәрнең мәдәният һәм сәнгать үзәге.

3 февраля 1944 года Альметьевский районный Исполнительный комитет принимает решение об открытии в городе театра. 20 марта этого же года Совет Министров ТАССР это решение утверждает. Альметьевский театр начинает свою деятельность как колхозно-совхозный театр, в 1951 году преобразуется в драматический театр, до 1985 года работал как передвижной. Первоначально театр располагался в здании местного Дома культуры, в 1973 году получает собственное помещение, а в 1985 году для театра было переоборудовано здание Дома культуры.

Труппа формировалась из выпускников Казанского театрального училища и участников художественной самодеятельности. В конце мая 1944 года режиссером А.Галеевым был поставлен первый спектакль – «Кайту» («Возвращение») Р.Ишмурата, в 1945 году – «Минникамал» М.Амира,

заложившие основу репертуара и продемонстрировавшие творческие возможности нового коллектива.

В 1946–1950 годах главный режиссер К.Халяпов поставил пьесы «Давыллар эчендә» («В бурю»), «Тагир Биккинин» Н.Гайсина, «Егет сүзе», («Слово джигита») Э.Шамиля, «Серләр» («Тайны») А.Ахмета.

В 1950–1954 годах репертуар театра обогатился пьесами А.Афиногенова «Машенька», Ш.Камала «Хаҗи әфәнде өйләнә» («Хаджи-эфенди женится», режиссер Т.Кичубаев), А.Арбузова «Яшьлек белән очрашу» («Встреча с юностью», режиссер С.Булатов), И.Франко «Урланган бәхет» («Украденное счастье», режиссер Г.Юсупов) и др.

В 1954–1958 годах главным режиссером театра является Саид Булатов. Спектакли в его постановке – «Томан арты» Ш.Камала («За туманом»), «Соңгы очрашу» С. Кальметова («Последняя встреча»), «Нурихан», «Рамай» М. Хасанова, «Яшь йөрәкләр» Ф.Бурнаша («Молодые сердца») – становятся серьезной школой актерского мастерства.

Большой вклад в укрепление коллектива профессиональными кадрами, рост актерского мастерства внес Габдулла Юсупов, возглавлявший театр в 1963–1966 годы. При нем в театре организуется студия. В репертуаре театра появляются пьесы молодых драматургов Г.Ахунова, А.Гилязова, Т.Миннуллина, Ш.Хусаинова.

В 1969–1972, 1975–1983 годах театр возглавляет Гали Хусаинов. Поставленные им пьесы «Козы-Көрпеш и Баян-Сылу» («Козы-Корпеш и Баян-Сылу», Г.Мусрепов), «Анам кыры» («Материнское поле» по повести Ч.Айтматова, 1971, 1977), «Тальян моңы» («Мелодия тальянки», Ш.Бикчурин), «Тылсымлы кыз» («Трактирщица», К.Гольдони), «Кар астында кайнар чишмә» («Под снегом горячий родник», А.Гилязов), «Ай булмаса, йолдыз бар» («Если нет луны, есть звезды», Т.Миннуллин; в 1978 году драматург, режиссер Г.Хусаинов, испольнительница главной роли Д.Кузаева удостоены Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая), «Антигона» (Ж.Ануйя) выводят театр на новые рубежи, обозначают творческую зрелость коллектива.

В 1983–1988 годах главным режиссером работает Рустем Абдуллаев. Наибольший резонанс вызвали поставленные им спектакли: «Җилкәнсезләр» («Без ветрил») К.Тинчурина, «Ә таңнар гүзәл тынлыкта иде» («А зори здесь тихие...») Б.Васильева, «Сармат кызы Сәринә» («Сирина – дочь Сармата») Н.Фаттаха.

В 1991 году в театр вновь возвращается Закия Туишева (в 1964–1976 годах в качестве режиссера поставила 21 спектакль) и создает широкомасштабные сценические полотна. Коллектив успешно выступает на

театральном фестивале им. К.Тинчурина в 1992 году со спектаклем «Яшь йөрәкләр» («Молодые сердца») по пьесе Ф.Бурнаша (режиссер З.Туишева).

В последующие годы главными режиссерами были К.Валиев, Г.Каюмов.

Театр участвует в международных, всероссийских театральных фестивалях, награждается дипломами конкурсов.

Сегодняшний Альметьевский татарский драматический театр – один из признанных коллективов Республики Татарстан – живет напряженной творческой жизнью, много гастролирует; широко известен как в самой республике, так и далеко за её пределами, является подлинным центром культуры нефтяного региона Татарстана.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***


**Гобәйдуллин Х.** Әлмәт татар дәүләт драма театры //Татар совет театры: (очерклар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 370-389.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан, 2014. – 584 б. – Әлмәт татар дәүләт драма театры. – Б. 36-38.

**Исмәгыйлова Ф.** Үткәннән – бүгенгегә //Казан утлары. – 2014. – № 12. – Б. 142-147.

**Зәйнуллина Г.** Әлмәтчә – заманча һәм сәнгатьчә! //Идел. – 2014. – № 3. – Б. 72-75.

**Кашапова С.** Әлмәттә театр бәйрәме //Мәдәни җомга. – 2014. – 12 дек. – Б. 9.

**Хәбибуллина Л.** 70 еллык театр әнә шундый булырга тиеш //Шәһри Казан. – 2014. – 2 дек. – Б. 9.

**Гыймранова Д.** Чынлык һәм ихтималлык арасы //Мәдәни җомга. – 2006. – 31 март. – Б. 19.

**Гимранова Д.** Сценическая жизнь Альметьевска //Альметьевск=Әлмәт. – Казань, 2003. – С. 518-530. (Альметьевская энциклопедия).

**Зайнуллина Г.** Молодость 70-летнего театра //Идель. – 2014. – № 3. – С. 48-52.

**Ахметов Р.** Театр из Альметьевска //Звезда Поволжья. – 2014. – 23-29 янв. – С.1-2.

**Исмагилова Ф.** Несмотря ни на что! /беседа с директором //Идель. – 2011. – № 3. – С. 52-55.

**15 апрель** **Шәмси Хәбибулла улы Хамматов**
**15 апреля** **Шамси Хабибуллович Хамматов**
**1919–1988**
**тууына 100 ел**
**100 лет со дня рождения**

Күренекле журналист, публицист Шәмси Хәбибулла улы Хамматов 1919 елның 15 апрелендә Свердловск өлкәсе Түбән Серга районының Аккүл авылында крестьян гаиләсендә туа. Үзенең хезмәт эшчәнлеген ул 1937 елда Свердловск өлкәсенең Шокурово урта мәктәбе укытучысы булып башлый. Мәктәп директоры, комсомолның Түбән Серга райкомы секретаре, КПСС райкомы инструкторы булып эшли.

Ш.Хамматовның оештыру таланты, принципиальлеге һәм әдәби сәләте журналистикада аеруча тулы ачыла. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1945 елда ул «Кызыл Татарстан» республика газетасы редакторы урынбасары итеп билгеләнә.

Аннары Ш.Хамматов Мәскәүдә КПСС ҮК каршындагы Җәмгыять белеме академиясендә укый, башкала һәм Казан архивларында фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнә, тарих буенча кандидатлык диссертациясе яклый.

1951–1960 елларда Ш.Х.Хамматов КПССның Татарстан өлкә комитетында мәктәпләр бүлеге мөдире, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр, «Татарстан коммунисты» журналының баш редакторы, партия өлкә комитеты каршындагы КПСС тарихы институты директоры булып эшли.

1960–1983 елларда Шәмси Хәбибулла улы «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясен җитәкли, «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» республика газеталарының берләшкән редакциясе редакторы була.

КПСС өлкә комитеты бюросы әгъзасы, ТАССР Югары Советы депутаты, Татарстан Журналистлар союзы идарәсе рәисе, СССР Журналистлар союзы идарәсе әгъзасы буларак, Ш.Х.Хамматов зур җәмәгать эше алып бара.

Хезмәттәге уңышлары өчен Ш.Х.Хамматов Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, Почет билгесе орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. Аңа РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

Ш.Х.Хамматов 1988 елның 21 ноябрендә вафат була.

Видный журналист, публицист Шамси Хабибуллович Хамматов родился 15 апреля 1919 года в деревне Перепряжке (Аккүл авылы) Нижне-Сергинского района Свердловской области в семье крестьянина. Свою трудовую деятельность начинает в 1937 году учителем Шокуровской средней школы Свердловской области. Работал директором школы, секретарем Нижне-Сергинского райкома комсомола, инструктором райкома партии.

Организаторский талант, принципиальность и литературные дарования Ш.Хамматова проявляются в журналистике. В 1945 году после окончания Высшей партийной школы при ЦК КПСС он назначается заместителем редактора республиканской газеты «Кызыл Татарстан».

Затем Ш.Хамматов учится в Москве в Академии общественных наук при ЦК КПСС, занимается в архивах столицы и Казани исследовательской работой и защищает кандидатскую диссертацию по истории.

С 1951 по 1969 год Ш.Х.Хамматов заведует Отделом школ Татарского обкома КПСС, старшим научным сотрудником Института языка, литературы и истории КФ АН СССР, главным редактором журнала «Коммунист Татарии», директором Института истории КПСС при обкоме партии.

С 1960 по 1983 год Шамси Хабибуллович возглавляет редакцию газеты «Социалистик Татарстан», является редактором объединенной редакции республиканских газет «Социалистик Татарстан» и «Советская Татария».

Он ведет большую общественную работу как член бюро обкома КПСС, депутат Верховного Совета ТАССР, председатель правления Союза журналистов ТАССР, член правления Союза журналистов СССР.

За трудовые заслуги Ш.Х.Хамматов награжден орденами Трудового Красного Знамени, Дружбы народов, «Знак Почета» и медалями. Ему присвоено почетное звание заслуженный работник культуры РСФСР. Ш.Х.Хамматов умер 21 ноября 1988 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***


**Хамматов Ш.Х., Әгъзамов Ф.И.** Матбугат – дуслык байракчысы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 247 б.

**Хамматов Ш.** Муса Җәлил – партия солдаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 168 б.: рәс.

**Хамматов Ш.Х.** Газета һәм әдәбият дуслыгы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 184 б.

**Хамматов Ш.Х.** Муса Җәлил, аның каләмдәшләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 207 б.

**Хамматов Ш.Х.** Казанская организация большевиков в годы первой русской революции. – Казань: Таткнигоиздат, 1955. – 127 с.

**Хамматов Ш.Х.** О союзе рабочих и крестьян в Татарии (нояб. 1917 – 1920 гг.). – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 136 с.

**Хамматов Ш.Х.** Муса Джалиль – солдат партии. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 168 с.

**Ризванов Г.** Шәмси ага турында; **Мансуров З.** Тугрылык дәвамчысы //«Ватаным Татарстан» газетасына – 90! – Казан: Идел-Пресс, 2009. – Б. 90, 119-122.

**Низамов И.** Олы булсаң, кече бул: Шәмси Хамматов турында; **Гәрәев М.** Акылы – алтын, уйлары диңгез иде //Һич онытасым юк... [«Ватаным Татарстан» газетасының 95 еллыгына карата]. – Казан, 2013. – Б. 64-66, 89-93.

**Хабибуллин И.** Шамси Хабибуллович Хамматов: к 80-летию со дня рождения; **Валеев Ш.** Он всегда стоял у истоков нового; **Г.И.Усманов:** «Помню я его хорошо…» /интервью взял Ш.Мирсаяпов //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1999. – № 1/2. – С. 189-190, 191-195, 196-198.

**5 июнь** **Леонид Яковлевич Елькович**
**5 июня** **1919–2003**
**тууына 100 ел**
**100 лет со дня рождения**

График, сәнгать белгече, педагог Леонид Яковлевич Елькович 1919 елның 5 июнендә Петроград шәһәрендә туа. Саратов университетының физика-математика факультетын (1941), Саратовта эвакуациядә вакытта Ленинград университеты аспирантурасын тәмамлый, университет белән бергә Ленинградка кайта.

1952–1958 елларда Алма-Ата һәм Ашхабад музейларында эшли.

1958 елдан Л.Я.Ельковичның тормышы Казан белән бәйле. 1958–1964 елларда ул РСФСР Рәссамнар берлегенең Татар бүлегендә җаваплы секретарь вазыйфасын башкара, 1966–1981 елларда Казан төзүче-инженерлар институтында, 1983 елда Казан сынлы сәнгать училищесында сәнгать тарихын укыта.

Л.Я.Елькович, сатирик графика һәм карикатура остасы. Аның рәсемнәре 1935 елдан басыла башлый. Ул – 1961 елда Казан агитплакат остаханәсен оештыручыларның берсе, 1950–1980 елларда «Чаян» журналының даими хезмәткәре. Рәссамның сатирик графикадагы төп иҗади казанышлары сәяси карикатуралар белән бәйле: «Кара тәнлене кертегез», «Саулык телим, генералым» һ.б. Көнкүреш карикатуралары көлкеле вакыйгаларга бай булуы белән үзенчәлекле.

Л.Я.Елькович иҗат итү белән бер үк вакытта тәнкыйтьче һәм сәнгать белгече буларак та актив эшли. Аның хезмәтләре арасында республика рәссамнарына багышланган монографияләр, альбомнар, буклетлар бар. Ул сатирик графика үсешен дә тирәнтен өйрәнә. Л.Я.Елькович бик күп күргәзмәләрдә катнаша: «Агит-тәрәзәләр»дән (Саратов, 1942) башлап, 1958 дан ТАССР рәссамнарының республика күргәзмәләрендә, шулай ук Идел буе рәссамнарының төбәк (1960–1990), Бөтенроссия, Бөтенсоюз, Халыкара һәм чит илләрдә үткәрелгән совет сәнгате күргәзмәләрендә.

Рәссамның хезмәтләре Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Әлмәттәге Картиналар галереясында, Габроводагы Сатира һәм юмор музеенда (Болгария) саклана.

1990 елда Л.Я.Ельковичка Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

Л.Я.Елькович 2003 елның 23 мартында вафат була.

График, искусствовед, педагог Леонид Яковлевич Елькович родился 5 июня 1919 года в Петрограде. Окончил физико-математический факультет Саратовского университета (1941), аспирантуру Ленинградского университета, находившегося в эвакуации в Саратове, вместе с университетом возвращается в Ленинград.

В 1952–1958 годах работает в музеях Алма-Аты и Ашхабада.

С 1958 года Л.Я.Елькович живет и работает в Казани. В 1958–1964 годах работает в должности ответственного секретаря Татарского отделения Союза художников РСФСР. В 1966–1981 годах преподает историю искусств в Казанском инженерно-строительном институте, в 1983 – в Казанском художественном училище.

Л.Я.Елькович – мастер сатирической графики и карикатуры. Его рисунки начинают печататься с 1935 года. Он один из организаторов казанской мастерской агитплаката (1961), постоянный сотрудник журнала «Чаян» (1950–1980-е годы). Его основные творческие достижения связаны с политической карикатурой: «Введите черномазого», «Здравия желаю, мой генерал» и др. Бытовую карикатуру художника отличают доступность сюжета, обилие юмористических ситуаций.

Паралельно с художественным творчеством Л.Я.Елькович активно выступает как художественный критик и искусствовед. Среди его трудов – монографии, альбомы, буклеты, посвященные ведущим художникам республики. Опираясь на собственный опыт, он углубленно изучает развитие сатирической графики.

Л.Я.Елькович – участник многих выставок: «Агит-окно» (Саратов, 1942); с 1958 года являлся постоянным участником республиканских выставок хужожников ТАССР, а также зональных выставок Поволжья; Всероссийских, Всесоюзных, Международных выставок и выставок советского искусства за рубежом.

Работы художника хранятся в Государственном музее изобразительных искусств РТ, Национальном музее РТ, Картинной галерее г.Альметьевска, Музее сатиры и юмора г. Габрово (Болгария).

В 1990 году Л.Я.Ельковичу присвоено почетное звание заслуженного работника культуры Республики Татарстан.

Л.Я.Елькович умер 23 марта 2003 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Елькович Л.** Лотфулла Фаттахов. – М.: Сов. художник, 1960. – 73 с.: ил.

**Елькович Л.** Николай Дмитриевич Кузнецов. – М.: Сов. художник, 1962. – 75 с.: ил.

**Елькович Л.** На линии огня. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. – 127 с.

**Червонная С.М.** Художники Советской Татарии: (мастера изобразительного искусства Союза художников ТАССР). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 464 с.

**15 июнь** **Николай Григорьевич Чеботарев**
**15 июня** **1894–1947**
**туунына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Күренекле математик Николай Григорьевич Чеботарев 1894 елның 15 июнендә Каменец-Подольский шәһәрендә юрист гаиләсендә туа. Губерна ирләр гимназиясендә укый. 1912 елда Н.Чеботарев Киев университетына укырга керә, аналитик һәм алгебраик функцияләр теориясе буенча профессор Д.А.Гравеның семинарларына йөри. Үзе дә бу темага яза башлый. 1916 елда ул университетта профессор исеме алырга әзерләнү өчен калдырыла; 1918 елда ул профессор дәрәҗәсенә лаек була.

1918–1921 елларда ул университетта приват-доцент, шулай ук Киев Югары уку йортларында укыта; 1921 елдан ул Одессада үзенең тикшеренүләрен үткәрә, 1927 елда докторлык диссертациясен яклый.

1927 елда Н.Г.Чеботарев Казан университетына математика кафедрасы мөдире итеп чакырыла. Казанда яшәү чоры аның өчен гаять нәтиҗәле булып чыга. Биредә ул үзенең математика буенча монографияләрен яза, алар үзәк нәшриятларда басылып чыга; СССРда беренче булып топология буенча дәреслек һәм Россиядә революциядән соң беренче булып Эварист Галуа теориясе нигезләре турында дәреслек яза, Н.И.Лобачевский хезмәтләре җыелмасын әзерләүдә катнаша; сәләтле яшьләрне университетка җәлеп итү өчен укучыларның математика олимпиадаларын оештыра.

Н.Г.Чеботарев хезмәтләре бөтен илләргә таныла. Дөньяның иң зур алгебрачыларыннан берсе буларак, ул 1932 елда Цюрихта Бөтендөнья математиклар конгрессында Эварист Галуа вафатының 100 еллыгына багышланган доклад белән чыгыш ясый.

Николай Григорьевичның аеруча зур хезмәтләренең берсе – аның Казанда Математика һәм механика фәнни-тикшерену институтын оештыруы, аның беренче директоры булуы. Ул институт 1947–2011 елларда аның исемен йөртә.

Бөек Ватан сугышы елларында Н.Г.Чеботарев оборона темасына – атканда диңгез туплары көпшәләренең вибрациясен тикшеренүгә алына, механиканың һәм сыгылмалык теориясенең кирәкле бүлекләрен өйрәнеп, тиешле исәп-хисаплар ясый, ә математика буенча үз өлкәсендә бу елларда аеруча нәтиҗәле эш алып бара.

Галимнең фәнни казанышлары СССР ФА тарафыннан югары бәяләнә. 1929 елда ук Н.Г.Чеботарев СССР Фәннәр академиясенә мөхбир әгъза итеп

сайлана. 1943 һәм 1946 елларда ул СССР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп тәкъдим ителә, ләкин идеологик сәбәпләр аркасында узмый.

1945 елда ул СССР Фәннәр академиясе Казан физика-техника институтының беренче директоры була.

Галим дөньяга танылган Казан алгебра мәктәбенә нигез сала, күренекле галимнәр һәм педагоглар тәрбияли.

Н.Г.Чеботарев Ленин ордены һәм ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә, аңа РСФСРның һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелә; «Проблемы резольвент» монографиясе өчен аңа беренче дәрәҗә Сталин премиясе (1948, үлгәннән соң) бирелә.

Н.Г.Чеботарев 1947 елның 2 июлендә катлаулы операциядән соң Мәскәүдә вафат була. Галимнең кабере Казанның Арча зиратында.

1994 елда Казанда Н.Г.Чеботаревның 100 еллык юбилеена багышлап «Алгебра и анализ» дигән зур  Халыкара конференция үткәрелде.

Выдающийся математик Николай Григорьевич Чеботарев родился 15 июня 1894 года в городе Каменец-Подольский в семье юриста. Учился в губернской мужской гимназии. С детства проявлял способности к математике.

В 1912 году  Н.Чеботарев поступает в Киевский университет; посещает семинары профессора Д.А.Граве по теории аналитических и алгебраических функций.  Пишет собственное сочинение на эту тему. В 1916 году оставлен при университете для подготовки к профессорскому званию.

В 1918–1921 годах – приват-доцент в университете, преподает в киевских высших учебных заведениях; в 1921–1927 годах в Одессе занимается научно-исследовательской деятельностью; защищает докторскую диссертацию (1927).

В 1927 году Н.Г.Чеботарев получает назначение в Казанский университет на должность заведующего кафедрой математики. Казанский период жизни был для него исключительно плодотворным. Здесь родились и увидели свет в центральных издательствах его монографии; был написал первый в СССР учебник по топологии и первый в послереволюционной России учебник об основах теории Эвариста Галуа; участвует в подготовке собрания сочинений Н.И.Лобачевского; организует школьные математические олимпиады для привлечения в университет талантливой молодежи.

Труды Н.И.Чеботарева получают всемирное признание. В 1932 году на Всемирном конгрессе математиков в Цюрихе ученый делает доклад, посвященный 100-летию со дня смерти Эвариста Галуа.

Особая заслуга Николая Григорьевича состоит в том, что он основал в Казани Научно-исследовательский институт математики и механики и был его первым директором; в 1947–2011 годах институт носил его имя.

В годы Великой Отечественной войны Н.И.Чеботарев занимается исследованием вибрации стволов морских орудий при выстреле: изучает необходимые разделы механики и теории упругости, делает расчеты, особенно продуктивно работает в области математики.

Научные заслуги Н.Г.Чебтарева были высоко оценены Академией наук СССР. В 1929 году он избирается членом-корреспондентом АН СССР; в 1943 и 1946 годах выдвигается в действительные члены АН СССР, но не проходит по идеологическим причинам.

В 1945 году стал первым директором Казанского физико-технического института АН СССР.

Ученый создает в Казани всемирно признанную алгебраическую школу и воспитывает видных ученых и педагогов.

Н.Г.Чеботарев награжден орденом Ленина, двумя орденами Трудового Красного Знамени, удостоен почетных званий заслуженного деятеля науки РСФСР и ТАССР, в 1948 году ему посмертно присуждена Сталинская премия первой степени  за монографию «Проблемы резольвент».

Н.Г.Чеботарев умер 2 июля 1947 года после тяжелой операции в Москве; прах ученого покоится на Арском кладбище в Казани.

В 1994 году в Казани состоялась Международная конференция «Алгебра и анализ», посвященная 100-летнему юбилею Н.Г.Чеботарева.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Малахальцев А.Т.** Математика классигы //Фәнни Татарстан. – 2004. – № 3. – Б. 56-59.

**Шафаревич И.Р., Морозов В.В.** Николай Григорьевич Чеботарев. 1894 – 1947. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 56 с.

**Дороднов А.В.** Николай Григорьевич Чеботарев (1894–1947) //Очерки истрии НИИ математики и механики имени Н.Г.Чеботарева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1989. – С. 110-119.

**Малахальцев А.Т.** Классик математики, так и не ставший академиком //Науч. Татарстан. – 2004. – № 3. – С. 44-48; Респ. Татарстан. – 2002. – 14 июня. – С. 11.

**Широкова О.** Продолжатель дела великого геометра //Казань. – 2009. – № 1. – С. 31-33.

**Морозов В.** Николай Григорьевич Чеботарев //Татарстан. – 1994. – № 3-4. – С. 72-81.

**Памяти выдающегося математика:** [открытие мемориальной доски Н.Г.Чеботареву] //Респ. Татарстан. – 1994. – 7 июня.

**15 июль** **Надир Дәүләт**
**15 июля** **Надир Давлет**
**1944**
**75 яшь тула**
**исполняется 75 лет**

Надир Дәүләт – Татарстанда һәм башка җирләрдә, Төркиядә һәм Ерак Көнчыгышта яшәүче төрки халыкларның һәм татарларның тарихын, мәдәниятен өйрәнүче зур галим. Ул 1944 елның 15 июлендә Мукден шәһәрендә (Маньчжурия, Кытай) туа. Аның әтисе Ибраһим Дәүләткилде, әнисе Рокыя Мөхәммәдиш милләтчелектә гаепләнеп, кулга алына.

Надирны тәрбиягә алган гаилә 1949 елда Төркиягә күчеп китә. 1967–1971 елларда Н.Дәүләт Истанбул университетында укый. Соңрак, 1972–1974 елларда укуын Германиядә, Мюнхендагы Максимилиан университетында дәвам итә; 1976–1982 елларда Истанбул университетының гомум төрки тарихы кафедрасында докторантура үтә.

Н.Дәүләт 1963–1967 елларда Төркиянең Анкара шәһәрендә Ислам энциклопедиясе, 1967–1971 дә – Төрки мәдәниятләр фәнни тикшеренү институты хезмәткәре; 1972–1984 елларда Мюнхенда «Азатлык» радиостанциясенең татар-башкорт редакциясендә эшли. Бер үк вакытта, 1970–1980 елларда, Төркиядә нәшер ителгән «Казан» журналының баш мөхәррире һәм мөхәррире була.

1984–2001 елларда Н.Дәүләт Истанбулдагы Мәрмәрә университетында укыта, университет каршындагы Төрки тикшеренүләр институты директоры вазыйфасын башкара; 1997–2005 елларда Хәрби Академиядә укыта; 2001–2007 елларда – Истанбулда Йәдитәпә институтында кафедра мөдире.

Н.Дәүләт 1985 елда тарих фәннәре докторы, 1992 елда профессор дәрәҗәсенә ирешә.

1989–1990 һәм 1996–1997 елларында Н.Дәүләт АКШның Колумбия һәм Висконсин университетларында лекцияләр укый.

Н.Дәүләт берничә ассоциация һәм фәнни оешмалар әгъзасы да булып тора: Төрки мәдәниятләр фәнни-тикшеренү институты; Төркия тарих җәмгыяте һ.б. Ул Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең чит илдәге әгъзасы.

Н.Дәүләтнең фәнни хезмәтләре төрки халыклар тарихына һәм халыкара мөнәсәбәтләргә карый. Төрле телләрдә күпсанлы мәкаләләре, 20 монографиясе нәшер ителгән, шулар арасында татар телендәге дүрт монографиясе бар.

Надир Давлет – крупный ученый в области истории и культуры тюркских народов и татар, проживающих в Татарстане и за его пределами, в частности, в Турции и на Дальнем Востоке. Он родился 15 июля 1944 года в городе Мукден (Маньчжурия, Китай). Родители Ибрагим Давлеткильде и Рукия Мухаммадиш были обвинены в национализме и репрессированы.

В 1949 году Надир, живший после ареста родителей с другой семьей, переезжает в Турцию. В 1967–1971 годах Н.Давлет учится в Стамбульском университете. Позже, в 1972–1974 годах учится в университете Максимилиан в Мюнхене (Германия); в 1976–1982 годах – в докторантуре Стамбульского университета на кафедре общей тюркской истории.

В 1963–1967 годах – сотрудник «Исламской энциклопедии», в 1967–1971 годах – сотрудник НИИ тюркской культуры в Анкаре (Турция); в 1972–1984 годах работает в редакции татаро-башкирских программ радиостанции «Свобода» в Мюнхене (ФРГ). Одновременно, в 1970–1980 – годах, является главным редактором и редактором издававшегося в Турции журнала «Казан».

В 1984–2001 годах Н.Давлет преподает в университете Мармара, является директором Института тюркских исследований при университете Мармара; в 1997–2005 годах – преподаватель Военной академии; в 2001–2007 годах – заведующий кафедрой истории университета Йедипе в Стамбуле.

Н.Давлет – доктор исторических наук (1985), профессор (1992).

В 1989–1990 и 1996–1997 учебных годах читает лекции в Колумбийском и Висконсинском университетатах США.

Н.Давлет является членом ряда ассоциаций и научных организаций: Института турецких и культурных исследований; Турецкого исторического общества и др.; иностранный член Академии наук Республики Татарстан; членом редколлегий многих изданий.

Основная тема научных работ Н.Давлета – история тюркских народов и международных отношений. Его многочисленные статьи и монографии изданы на разных языках, среди которых четыре моногорафии – на татарском языке.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Дәүләт Н.** Русия төркиләрнең милли көрәш тарихы (1905–1917) /тәрҗ. Р.Батулла; мөх-ре И.Һадиев. – Казан: Милли китап, 1998. – 399 б.

**Дәүләт Н**. Ерак Көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды? – Казан: Казан дәүләт ун-ты, 2005. – 99 б.

**Дәүләт Н.** 1917 октябрь инкыйлабы вә төрк-татар милләт мәҗлесе (Эчке Русия вә Себер мөселманнарының Милләт Мәҗлесе. 1917–1919. – Казан: Җыен: Милли китап, 2008. – 383б. – Библиогр.: Б. 357-383.

**Дәүләт Н.** Милләт белән Совет арасында: 1917 елгы Октябрь инкыйлабы: Русия төркиләренең яшәеш өчен көрәше /[төрекчәдән Р. Кадыйров тәрҗ.; мөх-р. И.Һадиев]. – Казан: Җыен, 2014. – 239 б.: портр.

**Дәүләт Н.** Төркиятчелек – минем язмышым //Идел. – 2013. – № 9. – Б.50-59.

**Гыйләҗев И.** Күренекле тарихчы Надир Дәүләт юбилее мөнәсәбәте белән //TATARIKA. – 2014. – № 2 (3). – Б. 229-235. – Инглиз һәм татар телләрендә.

**Батулла Р.** Дәүләтле Надир Дәүләт //Казан утлары. – 2000. – № 2. – Б. 145-147.

**22 июль** **Татарстан китап нәшрияты**
**22 июля** **Татарское книжное издательство**
**1919**
**оештырылуына 100 ел**
**100 лет со дня основания**

Татарстан китап нәшрияты – Россия Федерациясендә иң эре милли нәшриятларның берсе. 1919 елның 22 июлендә РКП (б)ның Казан губерна комитеты карары нигезендә Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге оеша. 1920 елның 3 ноябрендә РКП (б)ның Татарстан өлкә комитеты карары белән ул Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгосиздат) итеп үзгәртелә. ВКП (б) өлкә комитетының 1922 елгы 30 ноябрь карары нигезендә нәшрият «Татпечать» тресты белән берләштерелә һәм шулар нигезендә Татарстан нәшрият һәм матбугат комбинаты оеша. 1926 елда ул Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгиз) итеп үзгәртелә. 1927 елдан, аның составыннан К.Якупов исемендәге полиграфия комбинаты чыгарылып, «Гажур» газета-журналлар берләшмәсе кушылгач, Татарстан нәшрияты (Татиздат) исемен ала; 1933 тән, полиграфия комбинаты белән кабат берләштерүдән соң, – Татарстан дәүләт нәшрияты (Татгосиздат), 1954 тән – Татарстан китап нәшрияты (Таткнигоиздат).

1958 елда Татарстан полиграфия предприятиесе («Татполиграф») һәм Татарстан китап сәүдәсе (Таткниготорг) аерылып чыканнан хәзерге исемендә. Оешкан вакытта ук татар телендә фәнни-популяр, иҗтимагый-сәяси һәм матур әдәбият нәшер итүче иң зур оешма була.

1931 елга, барлык шәхси һәм кооператив нәшриятлар, басмаханәләр (фәнни әдәбият нәшер итүче югары уку йортларыннан кала) ябылганнан соң, – ТАССРдагы бердәнбер нәшрият, 1932 елдан (Үзәк нәшриятның Татарстан бүлеге бетерелгәннән соң) 1991 елга кадәр СССРдагы татар телендә әдәби басмалар бастыручы бердәнбер үзәк була.

1991 елда Татарстан китап нәшриятыннан «Мәгариф» нәшрияты бүленеп чыга. Нәшрият китапларының яртысыннан артыгын – татар, якынча өчтән бер өлешен рус телендә чыгара.

Татарстан китап нәшриятының бер гасырлык эшчәнлеге дәверендә биредә күп кенә күренекле язучылар, журналистлар, галимнәр, рәссамнар хезмәт куя.

2010 елда «Мәгариф» нәшрияты белән берләштерелә.

Нәшрият җитәкчеләре булып Н.Г.Мохтаров (1925–1927), С.З.Шәрәфетдинов (1927–1933), В.С.Шәфигуллин (1934–1939), М.Х Гайнуллин (1942–1944), С.Б.Вәлиди (1957–1963), Г.Г.Камалиев (1963–1973),

Г.Н.Шәрәфетдинов (1973–1987), Р.С.Мөхәммәдиев (1987–1989), Х.Ә.Әшрәфҗанов (1989–1998), Д.С.Шакиров (1998–2015), 2015 елдан И.К.Сәгъдәтшин эшлиләр.

Татарское книжное издательство – одно из крупнейших национальных издательств Российской Федерации. 22 июля 1919 года в соответствии с постановлением Казанского губкома РКП (б) было создано Казанское отделение Государственного издательства. 3 ноября 1920 года постановлением Татарского обкома РКП (б) оно было преобразовано в Татарское государственное издательство (Татгосиздат). На основании постановления обкома ВКП (б) от 30 ноября 1922 года издательство было объединено с трестом «Татпечать» и на их базе создан Татарский комбинат издательства и печати. В 1926 году он был реорганизован в Татарское государственное издательство (Татгиз). С 1927 года, после выведения из его состава полиграфического комбината им. К.Якуба и присоединения к комбинату газетно-журнального объединения «Гажур», получило название «Татарское издательство» (Татиздат), с 1933, после нового объединения с полиграфическим комбинатом, – «Татарское государственное издательство» (Татгосиздат), с 1954 года – Таткнигоиздат.

В 1958 году после отделения «Татполиграфа» и Таткниготорга издательство получило современное название. С момента создания оно является крупнейшим издательством художественной, научно-популярной и общественно-политической литературы на татарском языке.

К 1931 году, после закрытия всех частных и кооперативных издательств и типографий (кроме вузовских, издававших только научную литературу), оно стало единственным издательством в ТАССР, с 1932 года (после ликвидации Татарского отдела Центрального издательства) до 1991 года – единственным в СССР центром издания литературы на татарском языке.

В 1991 году из Татарского книжного издательства выделилось издательство «Магариф». Издательство выпускает более половины книг на татарском и около одной трети – на русском языках.

Сотрудниками Татарского книжного издательств являлись многие известные писатели, журналисты, ученые, художники.

В 2010 году объединено с издательством «Магариф».

Руководители издательства: Н.Г.Мухтаров (1925–1927), С.З.Шарафутдинов (1927–1933), В.С.Шафигуллин (1934–1939), М.Х Гайнуллин (1942–1944), С.Б.Валиди (1957–1963), Г.Г.Камалиев (1963–1973), Г.Н.Шарафутдинов (1973–1987), Р.С.Мухаммадиев (1987–1989),

Х.А.Ашрафзянов (1989–1998), Д.С.Шакиров (1998–2015), с 2015 года И.К.Сагдатшин.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Садә Г.** Кайда син, китап пайтәхете //Шәһри Казан. – 2009. – 17 июль.

**Хәмидуллин Л.** Милләтнең йөз аклыгы //Казан утлары. – 2014. – № 11. – Б. 138-148.

**Сәгъдәтшин И.** «Татарстан китап нәшрияты – ул бренд!» //Идел. – 2015. – № 7. – Б. 58.

**Сәгъдәтшин И.** «Tatkniga.ru – бөтен татар әдәбиятының үзәге ул» /әңгәмәдә А.Гомәрова //Идел. – 2017. – № 11. – Б. 19-21.

**Татар телендә электрон китаплар – бушлай!**: [нәшрият үзенең www.tatkniga.ru рәсми сайтында «Татар әдәбияты үзәге» проектын эшләтеп җибәрде] //Шәһри Казан. – 2017. – 10 окт.

**Каримуллин А.Г.** Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – 320 с.

**Книги Татарского книжного издательства за 9-10 пятилетки**. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. – 120 с.

**Здравствуй, Книга! = Исәнме, китап!** – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 252 с.

**Абдулхакова А.Р.** Татарская детская книга 1917–1991 гг.: эволюция и тенденции развития: монография /КГУКИ. – Казань, 2009. – 328 с.

**28 август** **Риза Газизов**
**28 августа** **1894–1981**
**туына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Күренекле тел галиме Риза (Ризаэтдин) Сәлахетдин улы Газизов 1894 елның 28 августында Вятка губернасы Алабуга өязе (хәзер Татарстанның Менделеев районы) Турай авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы мәдрәсәсендә ала. Аннары аны әтисе Блтач районындагы Түнтәр мәдрәсәсенә илтә. Өч ел укыгач, Риза Казанга килә һәм Татар укытучылар мәктәбенә укырга керергә әзерләнә. 1912–1916 елларда ул бу уку йортында гыйлем ала.

1918 елдан Р.Газизов педагогик һәм фәнни-педагогик эшчәнлектә. Хәзерге Алабуга, Биектау районы авыллары мәктәпләрендә татар һәм рус телләрен укыта, Татар-башкорт хәрби мәктәбендә, Казан авыл хуҗалыгы һәм Алабуга педагогия техникумнарында, Казан дәүләт университетында һәм Казан педагогика институтында белем бирә.

1939 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында: гыйльми секретарь, Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайткач, 1944–1961 елларда гыйльми хезмәткәр.

Р.С.Газизов – фәнни-педагогик эшчәнлек белән беррәттән, гомеренең күп өлешен татар тел гыйлеменең төрле тармакларын өйрәнүгә, сүзлекләр төзү эшенә, татар һәм рус телләрен укыту методикасы үсешенә биргән шәхес.

Галим чагыштырма грамматика төзү өлкәсендә актив эшли. Күпсанлы чагыштырма грамматикалары аша ул татар мәктәбендә ана теле һәм рус теле укыту методикасының лингвистик нигезләрен билгели.

Аның чагыштырма грамматикалары татар һәм рус телләрен чит тел буларак укыткан укытучылар өчен озак еллар буе дәреслек буларак кулланылып килә.

XX гасырның 20-30 еллары – Р.Газизов эшчәнлегендә чит аудиториягә һәм югары уку йортларында белем алучыларга татар телен өйрәтүдә яңа, фәнни нигезле формалар, метод һәм алымнар эзләү, дәреслекләр һәм программалар төзү чоры. Ул татарларга рус телен укыту буенча да күпсанлы программалар, дәреслекләр, укыту-методик әсбаплар төзү өлкәсендә күп эшли.

Татар лексикографиясен фәнни дәрәҗәгә күтәрүе Р.Газизовның бу өлкәдә казанышы булып тора. Ул ярты гасыр дәвамында татарча-русча,

русча-татарча сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә, сүзлекләр төзү принципларына карата фәнни мәкаләләр яза.

Р.С.Газизов тәрҗемә эше белән дә кызыксына, халык хуҗалыгының төрле өлкәләренә караган китапларны рус теленнән татарчага тәрҗемә итә.

1975 елда Р.С.Газизов, К.Насыйриның 150 еллык юбилее уңаеннан, галимнең «Әнмүзәҗ» хезмәтен гарәп графикасыннан кириллицага күчерә һәм рус теленә тәрҗемә итә, монда кулланылган терминнарның гарәпчә-татарча-русча сүзлекчәсен төзи.

Р.С.Газизов 1981 елның 4 июлендә вафат була.

Видный языковед Риза (Ризаутдин) Салахутдинович Газизов родился 28 августа 1894 года в деревне Тураево Елабужского уезда Вятской губернии (ныне Менделеевский район Республики Татарстан) в семье муллы. Учится в медресе своей деревни, в 1906 году поступает в медресе деревни Тюнтерь (ныне Балтасинский район РТ). Через три года уезжает в Казань, в 1912 году поступает в Татарскую учительскую школу, которую заканчивает в 1916 году.

Демобилизовавшись после гражданской войны, Р.С.Газизов активно включается в научно-педагогическую деятельность. С 1918 года преподает в сельских школах Елабужского и Высокогорского районов, в Татаро-башкирской военной школе, в Елабужском педагогическом техникуме. Многие годы читает лекции в Казанском государственном университете и Казанском педагогическом институте.

С 1939 года работает в Институте языка, литературы и истории ученым секретарем, в 1944–1961 годах – научным сотрудником.

Р.С.Газизов – один из крупнейших исследователей в области сравнительного (сопоставительного) изучения татарского и русского языков. Совместно с М.Курбангалеевым им была подготовлена «Грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка», претерпевшая несколько изданий (1924, 1928, 1931, 1932, 1939). В последующие годы книга переиздавалась под разными названиями.

Р.С.Газизов активно участвует в составлении программ, учебников, учебных и методических пособий по татарскому и русскому языкам для учащихся начальных классов и среднего звена.

Значителен вклад Р.С.Газизова в разработку вопросов татарской лексикографии. В своих статьях он рассматривает основные вопросы современной татарской лексикографии, поднимая ее на новый уровень.

Р.С.Газизов в течение полувека занимается составлением русско-татарских и татарско-русских словарей; пишет научные статьи о принципах составления словарей.

Ученый занимается переводческой деятельностью: с русского на татарский язык им переводены книги по разным отраслям народного хозяйства.

К 150-летию К.Насыри Р.С.Газизов транслитерировал с арабской графики на кирилицу его научную грамматику «Әнмүзәҗ» («Энмюзядж»), перевел ее на русский язык, составил арабско-татарско-русский словарь терминов, данная грамматика была издана в 1975 году.

Р.С.Газизов умер 4 июля 1981 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Газизов Р.С.** Татарский язык: для самостоятельно изучающих. – Казань: Таткнигоиздат, 1960. – 251 с.

**Газизов Р.С.** Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. – Казань: Таткнигоиздат, 1966. – 368 с.

**Газизов Р.С.** Сопоставительная грамматика татарского и русского языков: фонетика и морфология. – Казань: Таткнигоиздат, 1977. – 272 с.

**Газизов Р.С., Асадуллин А.Ш.** Русский язык: учебник для 1 класса татарских школ. – Казань: Таткнигоиздат, 1977. – 144 с.

**Җамалетдинова Г.Ф.** Галим һәм педагог (күренекле тел галиме Р.С.Газизовның тууына 120 ел) //TATARIKA. – 2014. – № 2 (3). – Б. 236-242. –Инглиз һәм татар телләрендә.

**Ганиев Ф.А.** Күренекле лексикограф һәм контративист //Фән һәм тел. – 2010. – № 1. – Б. 20-25.

**Мөхәммәтшин А.** Галим һәм педагог //Мәйдан. – 2004. – № 9. – Б. 110.

**Җамалетдинова Г.Ф.** Күренекле методист-галим, лексикограф //Мәгариф. – 2003. – № 7. – Б. 15.

**Замалетдинова Г.Ф.** Ризаутдин Газизов: лингвистическое и методическое наследие. – Казан: Магариф, 2005. – 135 с. – Труды Р.С. Газизова. – С. 122-134.

**Замалетдинова Г.Ф.** Газизов Ризаутдин Салахутдинович //Казанская лингвистическая школа: книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – С. 60-63.

**Сабирова К.С.** Ризаутдин Салахутдинович Газизов: к восьмидесятилетию со дня рождения //Сов. тюркология. – 1979. – № 4. – С. 108.

**15 сентябрь** **Михаил Георгиевич Худяков**
**15 сентября** **1894–1936**
**тууына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Тарихчы галим, археолог, этнограф Михаил Георгиевич Худяков 1894 елның 15 сентябрендә Вятка губернасы Малмыж шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә туа.

Башта Казанның 1 нче ирләр гимназиясендә, аннары 1913–1918 елларда Казан университетының тарих-филология факультетында укый. Студент елларында ук фән белән мавыга, Казан университеты каршында эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлегендә катнаша; 1914 елда Болгарда, 1915 елда Биләрдә үткәрелгән археологик экспедицияләрдә катнаша.

1918–1924 елларда М.Г.Худяков Казанда эшли: мәктәптә укыта, Казан һәм аның тирә-ягында мәдәни-тарихи экскурсияләр үткәрә; 1919 елдан Губерна музеенда (1920 елдан Татарстан Республикасының Үзәк музее) – археология бүлекчәсендә саклаучы хезмәткәр, аннары тарих-археология бүлеге мөдире; бер үк вакытта Татарстан АССР Мәгариф халык комиссариатында музей бүлеге хезмәткәре була. 1919–1922 елларда ул Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография институтында (1921 елдан Көнчыгыш академиясе) укыта. Ул Казанда «Татарны фәнни өйрәнү җәмгыят»ен төзүчеләрнең берсе, аның җаваплы секретаре булып тора; беренчеләрдән булып, ТАССРның археологик картасын төзи; туган шәһәре Малмыжда музей оештыруда катнаша.

1920–1924 елларда М.Худяков Казанда көндәлек матбугатта, бигрәк тә «Казанский музейный вестник» һәм «Вестник просвещения ТАССР» журналларында үзенең хезмәтләрен бастыра. Аның басылган «Бөек шәһәр хәрабәләре» («Развалины Великого города», 1921), «Идел буе мөселман мәдәниятенә 1000 ел» («1000-летие мусульманской культуры в Поволжье», 1922), «Татар әдәбиятын тәрҗемә итү зарурлыгы» («О необходимости переводов татарской литературы)», «Казан татарларының агачтан йорт төзү осталыгы» («Деревянное зодчество казанских татар», 1924) һәм башка хезмәтләре ул вакытта үзенең темасы белән дә, проблеманың куелышы белән дә бик яңа һәм үзенчәлекле, башкаларга охшамаган була.

Алар арасында 1923 елда дөнья күргән «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» хезмәте аеруча зур игътибарга лаек. М.Худяковның бу китабы – рус тарихчылары арасында Казан ханлыгына багышланган беренче хезмәт. Ул Россиядә революциядән соң беренче елларда татар дәүләтчелеге тарихы турында аеруча әһәмиятле археологик һәм архив материалларына нигезләнеп язылган.

М.Худяков 1926–1929 елларда Ленинградтагы Матди культура тарихы академиясендә аспирантурада укый һәм 1931 елдан шунда ук эшли дә башлый. Галимнең фәнни тикшеренүләренең темасы шулай ук кала – Идел

буенда мөселман мәдәниятенә багышлана. Шуларны бәяләү нәтиҗәсендә әлеге академия аңа 1936 елда тарих фәннәре докторы дәрәҗәсен бирә.

1936 елның 9 сентябрендә М.Худяков «троцкийчы, халык дошманы» дип кулга алына һәм шул ук елның 19 декабрендә СССР Югары Советы Хәрби коллегиясе галимне атарга хөкем итә, бу карар көне белән җиренә җиткерелә.

Галим 1957 елда аклана, әмма аның мирасы әле аннан соң да шактый вакыт укучылардан яшереп тотыла. Бары 1980 нче еллар ахырында гына аның кайбер әсәрләре татар һәм рус телләрендә нәшер ителә башлый.

М.Г.Худяков рус тарихчылары арасында гыйльми объективлыгы, Идел буе халыклары, бигрәк тә татар халкы үткәнен тирәнтен өйрәнүе, дәлилле сурәтләве белән кискен аерылып тора.

Ученый-историк, археолог, этнограф Михаил Георгиевич Худяков родился 15 сентября 1894 года в городе Малмыж Вятской губернии в купеческой семье.

Получает образование в 1-ой Казанской мужской гимназии, в 1913–1918 годах учится на историко-филологическом факультете Казанского университета. В студенческие годы активно сотрудничает с Обществом археологии, истории и этнографии при Казанском университете; участвует в своих первых профессиональных раскопках и разведках в Булгаре (1914) и Билярске (1915).

В 1918–1924 годах М.Худяков работает в Казани: преподает в школе, проводит культурно-исторические экскурсии по Казани и ее окрестностям; с 1919 года служит хранителем археологического отделения, затем заведующим историко-археологическим отделом Губернского музея (с 1920 года Центральный музей Татарской Республики), одновременно в музейном отделе Народного комиссариата просвещения Татарской АССР. В 1919–1922 годах преподает в Северо-Восточном археологическом и этнографическом институте (с 1921 года Восточная академия). Является одним из организаторов и секретарей Научного общества татароведения; первым составляет археологичекую карту ТАССР; участвует в организации музея в родном Малмыже.

В 1920–1924 годах М.Худяков активно публикуется на страницах «Казанского музейного вестника» и «Вестника просвещения ТАССР». Его статьи и по тематике, и по постановке проблем звучали в то время свежо и оригинально: «Развалины Великого города» (1921), «1000-летие мусульманской культуры в Поволжье» (1922), «О необходимости переводов татарской литературы», «Деревянное зодчество казанских татар» (1924) и многие другие.

В ряду его научных работ особое место занимают «Очерки по истории Казанского ханства», напечатанные в 1923 году. Книга М.Худякова – одна из первых работ русских историков, посвященных Казанскому ханству, основана на большом количестве археологических и архивных

материалов, является крупным исследованием истории татарской государственности, проделанным в России в первые послереволюционные годы.

В 1926–1929 годы М.Г.Худяков учится в аспирантуре Ленинградской академии истории материальной культуры, а с 1931 года работает там, но тематика научных исследований остается прежней – мусульманская культура Поволжья. В 1936 году М.Г.Худякову присвоена ученая степень доктора исторических наук.

9 сентября того же года он был арестован и 19 декабря 1936 года расстрелян как «троцкист и враг народа». Жестокий каток репрессий подмял под себя многих талантливых, имеющих собственное мнение людей. Не уберегся от него и М.Г.Худяков.

Лишь через двадцать лет, в 1957 году, ученый был реабилитирован, но и после этого его труды не переиздавались и поэтому оказались недоступными современному читателю. Лишь в конце 1980-х годов появляются публикации некоторых его работ.

В ряду русских историков М.Г.Худяков отличается научной объективностью, глубиной исследования, аргументированным отображением прошлого народов Поволжья, прежде всего – татарского народа.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Михаил Худяков**: тарихи-документаль җыентык /төз. М.Госманов, Җ.Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2011. – 704 б. – Библиогр.: Б. 682-691. – («Шәхесләребез» сериясе).

**Худяков М**. Очерки по истории Казанского ханства /вступ. слово М.А.Усманова. – 3 изд., исправ. и доп. – М.: Инсан, 1991. – 320 с. – Библиогр.: С. 314-317.

**Худяков М.** Очерки по истории Казанского ханства /вступ. слово М.А.Усманова. – Репринт. воспроизвед. – Казань: Фонд ТЯК, 1990. – 310 с.

**Худяков М.** Очерки по истории Казанского ханства. – Казань: Гос. изд–во, 1923. – 304 с.

**Худяков М.** Мусульманская культура в Среднем Поволжье //Знаменитые личности: историко-биографический сборник. – Казань: Жиен, 2013. – С. 368-381. – Об авторе «Вернувшийся из небытия». – С. 359-368.

**Худяков М.** 1000-летие мусульманской культуры в Поволжье /вступ. слово Ф.Байрамовой //Идель. – 1989. – № 1. – С. 44-47.

**Бәйрәмова Ф**. Михаил Худяковның гомер китабы //Мәд. җомга. – 2003. – 4, 11, 18 апр.; 2 май. – Б. 12.

**Госманов М.** Галимнең гыйбрәтле язмышы //Татарстан. – 1994. – № 9-10. – Б. 78-82.

**Заһидуллин И.** Талантлы тарихчы-романтик ядкаре: [тууына 120 ел] //Казан утлары. – 2014. – № 11. – Б. 115-125.

**Хәбибуллин М.** Тарихыбызга бер караш //Фән һәм тел. – 2001. – № 1. – Б. 15-20.

**Шәех Л.** Милләте белән урыс булган татар тарихчысы //Шәһри Казан. – 2004. – 17 сент.

**Харис Р.** Худяков: поэма // Татарстан. – 2001. – № 4. – Б. 68-71; Мәйдан. – 2011. – № 5. – Б.40-44.

**Байрамова Ф.** Михаил Худяков и история татарского народа. – Казань: Аяз, 2003. – 120 с.

**Усманов М.** Главный труд Михаила Худякова //Татарстан. – 1994. – № 9-10. – С. 140-143.

**Султанбеков Б.** Расстрелян как террорист //Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2002. – № 1/2. – С.107-126.

**Хузин Ф.** Михаил Георгиевич Худяков: [к 120-летию со дня рождения] //TATARICA. – 2014. – № 2 (3). – С. 246-248.

**Руденко К**. В плену во времени;  Куликов М. Распятая честь //Казань. – 2004. – № 3. – С.41-45; 46-55.

**Амиров К.Ф.** Казанских улиц имена /К.Ф.Амиров, Р.Х.Ахметзянова, Р.Г.Вениаминов. – Казань, 2008. – 592 с. –  М.Худяков. – С. 524-525.

**1 ноябрь** **Шәрәф Мөдәррис**
**1 ноября** **Шараф Мударрис**
**1919–1963**
**тууына 100 ел**
**100 лет со дня рождения**

Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис (Шәрәф Хәсиятулла улы Мөдәррисов) 1919 елның 1 ноябрендә хәзерге Татарстан Республикасының Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылында игенче гаиләсендә туа. Үз авылында башлангыч, күрше Мунчәли авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый. 1935 елда ул Казанга килә һәм педагогия институты каршындагы рабфакка укырга керә, аннары икееллык Укытучылар институтында укый.

Ш.Мөдәрриснең 1933 елдан ук шигырьләре матбугатта күренә башлый. 1937 елда «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. Әдәби тәрҗемә өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре дә шушы чорда башлана. 1941 елда аның турыдан-туры ориг иналдан тәрҗемәсендә чуаш язучысы К.Ивановның атаклы «Нарспи» поэмасы дөнья күрә.

1941 елның язында Ш.Мөдәррис Совет армиясенә алына һәм Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк алгы сызыкта була, башта минометчы, аннары фронт газеталарының хәрби корреспонденты була. «Тупчы Ваһап» исемле эпик поэмасында (1943) шагыйрь үзе аралашып яшәгән батыр сугышчыларның, гади солдатларның сугыштагы уй-хисләрен ватанпәрвәрлеген, каһарманлыгын чагылдыра.

1946 елның язында Ш.Мөдәррис Казанга кайта, республика газеталары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1956 елда читтән торып укып, М.Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый. Бу елларда шагыйрьнең әдәби иҗаты жанр һәм эчтәлек ягыннан төрлеләнә, тагын да үсә. Ул зур күләмле поэмалар, шигъри повестьлар, лирик һәм публицистик шигырьләр, юмор-сатира әсәрләре, хикәяләр яза, көндәлек матбугатта публицистик мәкаләләрен бастыра. Шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли: инглиз теленнән У.Шекспир сонетларын, «Король Ричард III» трагедиясен, Дж.Байрон, М.Шелли шигырьләрен, немецчадан Һ.Һейне шигырьләрен, русчадан А.С.Пушкин, Н.А.Некрасовның, шулай ук Т.Г.Шевченконың поэтик әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп бастыра.

Шекспир сонетларын тәрҗемә итү Ш.Мөдәрриснең үзенә дә бу катлаулы шигырь формасында иҗат итәргә этәргеч бирә. Ул татар поэзиясендә беренчеләрдән булып сонет жанрына юл ача, аның матур үрнәкләрен тудыра.

Ш.Мөдәррис Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Ш.Мөдәррис 1963 елның 28 апрелендә вафат була.

Поэт Шараф Мударрис (Шараф Хасиятуллович Мударрисов) родился 1 ноября 1919 года в деревне Нижний Каракитан нынешнего Дрожжановского района Республики Татарстан в семье крестьянина. Начальное образование получил в родной деревне, семилетнюю школу закончил в соседней деревне

Мунчали. В 1935 году приезжает в Казань, учится на рабфаке при Педагогическом институте, а затем и в самом институте.

Свои стихи Ш.Мударрис впервые публикует в 1933 году. Первый его поэтический сборник «Үскәндә» («Когда мы росли») опубликован в 1937 году. В этот период начинает заниматься литературным переводом. В 1941 году увидела свет поэма «Нарспи» чувашского писателя К.Иванова в переводе Ш.Мударриса.

Весной 1941 года Ш.Мударриса призывают в Советскую Армию. С первых дней Великой Отечественной войны поэт находится на передней линии: сначала минометчиком, затем литературным сотрудником фронтовых газет. В эпической поэме «Тупчы Ваһап» («Артиллерист Вагап», 1943) он отражает тему Великой Отечественной войны, размышления героев-воинов и простых солдат.

Весной 1946 года Ш.Мударрис вовращается в Казань, работает литературным сотрудником в редакциях республиканских газет. В 1956 году заочно заканчивает Литературный институт им. М.Горького в Москве. В эти годы литературное творчество поэта и по жанру, и по содержанию становится еще разнообразней. Он пишет большие поэмы, поэтические повести, лирические и сатирические стихи, памфлеты, рассказы, на страницах республиканских журналов и газет публикует литературно-публицистические статьи. Ш.Мударрис много работает и в области художественного перевода: с языка оригинала им переведены сонеты У.Шекспира, трагедия «Король Ричард III», стихи Дж.Байрона, М.Шелли, Г.Гейне, поэтические произведения А.С.Пушкина, Н.А.Некрасова, Т.Г.Шевченко.

Работа над сонетами Шекспира дала импульс его собственному творчеству в жанре этой сложной стихотворной формы. Написанные Ш.Мударрисом сонеты считаются непревзойденными в татарской поэзии.

За боевые заслуги награжден орденом Красной Звезды.

Ш.Мударрис умер 28 апреля 1963 года.

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Мөдәррис Ш.** Ильич нурлары: очерклар, публицистик мәкаләләр, памфлетлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 280 б.

**Мөдәррис Ш.** Дуслар күңеле: лирика, юмор-сатира, поэмалар /кереш сүз авт. Х.Госман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 368 б.

**Мөдәррис Ш.** Яшәү көче: әкият-поэма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 40 б.

**Мөдәррис Ш.** Тупчы Ваһап: поэмалар, шигырьләр, сонетлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 192 б.

**Мударрис Ш.** Во имя жизни: стихи, поэмы /пер с татар. В.Гончарова. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 104 с.

**Мударрис Ш.** Сквозь пепел дней: стихотворения, поэмы /пер. с татар.; вступ. ст. В.Гончарова. – М.: Худож. лит., 1974. – 174 с.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т.2 /[төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Шәрәф Мөдәррис. – Б. 139-140.

**Мәҗитов З.** Татар солдаты //Шәһри Казан. – 1999. – 5 нояб.

**Латыйп К.** Утлы күмерләрне хәтерләтте... //Мәдәни җомга. – 1999. – 5 нояб.

**Әхмәдулла Ш.** Нурлы сыны хәтер түрендә //Мирас. – 2002. – № 7. – Б. 22-32.

**Ихсанова Л.** Шагыйрьнең култамгасы //Казан утлары. – 2004. – № 11. – Б. 169-170.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. справочник. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Шараф Мударрис. – С. 301-302.

**Мингазова Э.** Он пел по-татарски на развалинах рейхстага //Казанские ведомости. – 2004. – 27 окт.

**2 ноябрь** **Гали Хөсәенов**
**2 ноября** **Гали Хусаинов**
**1919–2001**
**тууына 100 ел**
**100 лет со дня рождения**

Актер, режиссер Гали Кәрим улы Хөсәенов 1919 елның 2 ноябрендә Казан губернасы Свияжск (Зөя) өязенең (хәзер Яшел Үзән районы) Косяково кантоны Күгәй авылында туа. Счетовод, укытучы булып эшли. 1938 елда ул Татар академия театры каршындагы студияне тәмамлый.

Хәрби-пехота училищесында укыганнан соң, Г.Хөсәенов Сталинград өчен барган сугышларда катнаша. Каты яраланып, госпитальдә дәвалана, аннары демобилизацияләнә. 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Г.Хөсәенов 1949 елда Мәскәүдә А.В.Луначарский исемендәге Театр сәнгате институтының (ГИТИС) татар студиясен тәмамлый. 1949–1952 елларда ул Казан яшьләр театрының татар труппасы, Татар академия театры артисты; ТАССР Министрлар Советының сәнгать эшләре идарәсендә театр бүлеге мөдире булып эшли. Читтән торып Казан педагогия институтын тәмамлый.

1952–1969, 1972–1975 елларда Г.Хөсәенов Татарстан радиосында редактор, Казан телевидениесендә режиссер, баш режиссер булып эшли. Бу елларда ул «Шагыйрь Ф.Кәримнең иҗат портреты», «Актер П.Загорский», «Яңа өйдә», «Альбом битләре сөйли» һ.б. телевизион фильмнар төшерә. Шулай ук аның тарафыннан эшләнгән «Анам кыры» (Ч.Айтматов, 1965), «Муса» (Ш.Маннур, 1965) телевизион спектакльләре матур әдәбиятны пропагандалауда күренекле роль уйныйлар, мәдәният тарихында лаеклы урын алалар.

1969-1972, 1975-1983 елларда Гали Хөсәенов Әлмәт татар драма театрында баш режиссер булып эшли. Әлеге театрның иң кызыклы иҗади чоры Гали Хөсәенов исеме белән бәйле. Ул утызга якын спектакль куеп, Әлмәт театрын республиканың иң дәрәҗәле иҗат йортына әверелдерә. Аның куелышындагы «Козы-Көрпеш һәм Баян-Сылу» (Г. Мөсрепов, 1969), «Бишбүләк» (Т.Гыйззәт, 1970), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов, 1971), «Мирандолина» (К.Гольдони, 1975), «Кар астында кайнар чишмә», «Әгәр бик сагынсаң» (А.Гыйләҗев, 1976, 1979), «Шәмсекамәр» (М. Әблиев, 1976), «Антигона» (Ж.Ануйя, 1980), «Зөлфия» (К.Әмиров, 1982) һ.б. спектакльләр театрның үсеш этаплары булып санала, театр дөньясында зур яңалык буларак

кабул ителә.

1979 елда «Ай булмаса – йолдыз бар» (Т. Миңнуллин) спектакле өчен режиссер Гали Хөсәеновка Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе тапшырыла.

Гали Хөсәенов 1966 елда ТАССРның һәм 1982 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

Гали Кәрим улы Хөсәенов 2001 елның 26 июлендә Казанда вафат була.

2005 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә Яшел Үзән районы Күгәй авылы мәдәният йортына Г.К.Хөсәенов исеме бирелә.

Актер, режиссер Гали Каримович Хусаинов родился 2 ноября 1919 года в селе Кугеево Косяковского кантона Свияжской волости Казанской губернии (ныне Зеленодольский район Республики Татарстан). Работал счетоводом, учителем. В 1939 году окончил студию при Татарском академическом театре.

После окончания военно-пехотного училища участвовал в боях за Сталинград. Был ранен. После госпиталя был демобилизован. Награжден орденом Отечественной войны 2-ой степени, медалями.

В 1949 году Г.Хусаинов окончил Татарскую театральную студию при ГИТИСе им. А.В.Луначарского в Москве. В 1949–1952 годах – актер татарской труппы Казанского ТЮЗа и Татарского академического театра, заведующий театральным отделением Управления по делам искусств Совета министров Татарской АССР. Заочно окончил Казанский педагогический институт.

В 1952–1969 и 1972–1975 годах Г.Хусаинов работает редактором Татарского радио, режиссером, главным режиссером Казанской студии телевидения. В эти годы им были поставлены телевизионные фильмы «Творческий портрет поэта Ф.Карима», «Актер П.Загорский», «В новом доме», «Рассказывают страницы альбома» и др. Снятые им телевизионные спектакли «Материнское поле» (Ч.Айтматов, 1965), «Муса» (Ш.Маннур, 1965) сыграют заметную роль в пропаганде художественной литературы, занимают достойное место в истории татарской культуры.

В 1969–1972 и в 1975–1983 годах Гали Хусаинов работает главным режиссером Альметьевского татарского драматического театра. Самый интересный творческий период Альметьевского театра связан с его именем. Около тридцати постановок в его режиссуре способствовали творческому становлению театра, пришло настоящее признание, творческая обстановка стала наравне с большими творческими коллективами. Популярность театра

стала расти из года в год. Поставленные им «Козы-Корпеш и Баян-Сылу» (Г.Мусрепов, 1969), «Бишбуляк» (Т.Гиззат, 1970), «Әни килде» («Мама приехала», Ш.Хусаинов, 1971), «Мирандолина» (К.Гольдони, 1975), «Кар астында кайнар чишмә», «Әгәр бик сагынсаң» («Под снегом горячий родник», «Если очень соскучишься», А.Гилязов, 1976, 1979), «Шамсикамар» (М. Аблеев, 1976), «Антигона» (Ж.Ануйя, 1980), «Зульфия» (К.Амиров, 1982) и другие спектакли вывели театр на новые рубежи, обозначили творческую зрелость коллектива.

В 1979 году за спектакль «Ай булмаса – йолдыз бар» («Если нет луны, есть звезды») по пьесе Т.Миннуллина Г.Хусаинов удостоен Государственной премии им. Г.Тукая.

Г.К.Хусаинову присвоены почетные звания: 1966 год – заслуженный деятель искусств ТАССР, 1982 год – заслуженный деятель искусств РСФСР.

Г.К. Хусаинов умер 26 июля 2001 года в Казани.

В 2005 году Постановлением Кабинета министров Республики Татарстан Кугеевскому сельскому дому культуры Зеленодольского района присвоено имя Г.К.Хусаинова

***Укырга тәкъдим итәбез:***
***Советуем прочитать:***

**Галиәсгар Камал** исемендәге Татар дәүләт академия театры. 100 ел: альбом. 2 томда. Т.2. – Казан: Заман; Татар. кит. нәшр., 2009. – 567 б.: фотолар б-н. – Хөсәенов Гали Кәрим улы. – Б. 153. – Татар һәм рус тел.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан, 2014. – 584 б. – Хөсәенов Гали Кәрим улы. – Б. 542.

**Таһирова Ә**. Гали ага ядкаре //Мәдәни җомга. – 2004. – 19 нояб. – Б. 16.

**Хәбибуллина Л**. Чит җирләрдә саргаерга бераүгә дә язмасын //Шәһри Казан. – 1999. – 29 окт.

**Шиһапов М.** Кайт әле, Гали абый //Шәһри Казан. – 1999. – 19 нояб.

**Арсланов Г.** Жизнь по призванию //Респ. Татарстан. – 1999. – 27 нояб. – С. 7.

**17 ноябрь**
**17 ноября**

**Латыйф Җәләй**
**Латыф Заляй**
**1894–1966**
**тууына 125 ел**
**125 лет со дня рождения**

Күренекле тел галиме һәм әдәбият тәнкыйтьчесе Латыйф Җәләй (Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдинов) 1894 елның 17 ноябрендә Самара губернасы Мәләкәс өязе (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Чардаклы районы) Иске Кызылсу (русча атамасы Татарское Урайкино) авылында крестьян гаиләсендә туа. Мәләкәс мәдрәсәсендә белем ала.

1921 елдан Л.Җәләй Самара шәһәрендә: педагогия техникумында укытучы, балалар йорты мөдире. 1925–1928 елларда халык мәгарифе бүлегендә инспектор; 1928–1932 елларда Кузнецк, Мәләкәс шәһәрләрендәге партия мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Шушы чорда аның әдәби һәм гыйльми иҗат эшчәнлеге башлана.

1933 елда Л.Җәләй Казанга күчеп, укуын Казан педагогия институты аспирантурасында дәвам иттерә. Укуын тәмамлагач, шул ук институтның татар теле һәм әдәбият бүлегендә укыта.

1939 елда Казанда Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачылгач, Л.Җәләй тел белеме секторы мөдире итеп билгеләнә. 1942 елда «Татар теле тарихына карата кайбер материаллар» дигән хезмәте нигезендә кандидатлык диссертациясе яклый.

1944 елда Л.Җәләй Казан педагогия институтына кайтып укыта башлый һәм Казан университетында да студентларга лекцияләр укый.

1946 елдан СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында галим үзенең фәнни эшчәнлеген дәвам итә. Хезмәтләре татар теле тарихына, орфоэпиясенә, стилистикасына, диалектологиясенә, тарихи тел белеменә, татар халкының борынгы әдәби ядкәрләрен өйрәнүгә карый. «Татар теленең урта диалекты» дигән темага 1954 елда Мәскәүдә докторлык диссертациясе яклап, татар теле буенча беренче филология фәннәре докторы була, ә 1958 елда профессор исемен ала.

Л.Җәләй, күренекле тел галиме булудан тыш, әдәби тәнкыйтьче дә. К.Нәҗми, М.Әмир, Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, А.Шамов, С.Хәким, Ш.Мөдәррис һәм башка язучыларның иҗаты турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре; мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы да.

Л.Җәләй 1966 елның 1 августында Казанда вафат була.

Видный языковед и литературный критик Латыф Заляй (Латыф Залялетдинович Залялетдинов) родился 17 ноября 1894 года в деревне Татарское Урайкино (на тат. – Кызылсу) Мелекесского уезда Самарской губернии (ныне Чердаклинский район Ульяновской области) в семье крестьянина. Образование получает в Мелекесском медресе.

